***Беренче укытучы – Гариф Шәкүров.***

Гариф Зиатдинович Шәкүров Яңа Шөгер авылында иң белемле кеше буларак таныла. Ул Казанда белем алган, ә аның абыйсы Новгородта рус теле укыткан. Гариф Зиатдинович авылда иң беренче укытучы булган, ул 1916 нчы елда үзенең өендә мәктәп ача, ә укыта башлаган була ул 1908 нче елда. Аның хатыны Фахирә Корбангалиевна танылган татар мәгърифәтчесе Риза Фәхретдиннең туганы була, ул кызларны укыта. Алар балаларны гарәп телендә укырга, язарга өйрәтәләр, география, дин тарихы, татар тел буенча дәресләр алып баралар, ә кызлар шулай ук кул хезмәтенә, тегәргә һәм чигәргә өйрәнә.

Шәкүровлар Риза Фәхретдиннең :”Бала чакта алган тәрбияне бөтен дөнья халыклары да үзгәртә алмый” дигән сүзләрне искә алып эшлиләр. Алар белем биргән балаларның күбесе Бөек Ватан сугышыннан кире кайтмыйлар, ә кайберләре танылган кешеләргә әйләнә. Шуны да онытмаска кирәк, әгәр дә алар булмаса, авыл халкына балаларын Бөгелмәгә илтергә туры килер иде, ә болай ата-аналарга тынычрак- балалар өйдә, кирәк чакта ярдәм дә итә алалар. Шәкүровларның абруе авылда бик югары була, аларны ихтирам итәләр. Гариф Зиатдиновичка ихтирам зур булуын түбәндәге факт та раслый- авылда мәчет төзелгәч, аңа Коръәнне яхшы белүче кеше буларак, мулла булырга тәкъдим итәләр. 30 нчы елларда авылда кулакларга каршы көрәш башлана. Гариф

Зиатдинович гаиләсе зур була- улы һәм дүрт кызы, шуңа хуҗалыкта ат, сыер, биш сарык була. Боларның барысын да конфискациялиләр, өеннән куып чыгаралар, үзен кулга алалар. Фахирә Корбангалиевна ирен Бөгелмә төрмәсенә озата. Гаиләгә кая барырга? Хәбиров Минсәеф абзый һәм Әсма апа, үзләренең биш балалары булуга карамастан, Шәкүровлар гаиләсен дә сыендыралар (бу гамәл бик куркыныч санала, чөнки моның өчен Себергә дә җибәрергә мөмкин). Көзен Шәкүровлар яшерен рәвештә Бөгелмәгә, ә аннан Сулы авылына күчә. Гариф Шәкүров та шунда кайта, ләкин гаиләгә тыныч тормышта өч ел гына яшәргә туры килә. “Халык дошманнарын” эзләү башлангач, Гариф Зиатдинович Урта Азиягә китә, бер елдан әйләнеп кайта һәм алар Яңа Шөгер авылына кире кайталар. Шактый вакыт алар мунчада яшиләр, Гариф Шөгеров колхозда тырышып эшли, 1945 нче елда медаль белән бүләкләнә, лаеклы ялга китә, ә 1965 нче елда ул үлә.

Аның кызы Раушания Гарифовна сугыш елларында иптәш кызлары белән 1943 нче елда Шөгер нефть ятмасын ачуда катнаша, сугыштан соң Советлар Союзы Герое Самат Садриевка кияүгә чыга. Абыйсы һәм апалары шулай ук нефть өлкәсендә эшлиләр.

*Зиангирова Миннур Зиангировна.*

1917 елны Лениногорск районы Сугышлы авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа.1926-29 елларда Сугышлы башлангыч мәктәбендә укый. 1929-1933 елларда-Түбән Чыршылы җидееллык мәктәбендә белем ала. 1933-1936 елларда Бөгелмә мәктәп-педтехникумында укый. 1937-1941 елларда читтән торып КДПИ тәмамлый һәм татар теле һәм әдәбияте укытучысы белгечлеге ала. 1936-1940 елларда татар теле һәм әдәбиятен Федотовка,Урдалы,Куакбаш мәктәпләрендә укыта. 1940-1942 елларда Федотовка урта мәктәбе директоры була.1942 елның августында үзе теләп фронтка китә.Санинструктор,писарь булып Харьков стрелковый дивизиясенең Сталинград,Белгород, Харьков,Полтава фронтларында көрәшә. Батырлыклары,хәрби шартларда заданиеләрне төгәл үтәгәне өчен “За боевые заслуги”,”За оборону Сталинграда” медальләре,”Красная звезда” ордены белән бүләкләнә. 1944 елда өлкән сержант дәрәҗәсендә контузиядән соң туган якларына кайта. 1944 ел сентябрь-декабрендә ВКП(б)ның Шөгер райкомында инструктор булып эшли. 1944 елның декабрендә-1945 елның июнендә республика партия мәктәбендә укый. Аннан 1945-1947елларда Шөгер районы РОНОсында заведующий булып эшли. 1947-1967 елларда Иске Шөгер мәктәбендә укытучы, 1967-1974 елларда оештыручы булып эшли.“Халык мәгарифе отличнигы” билгесе белән бүләкләнә; РСФСРның атказанган укытучысы.

***Советлар Союзы Герое***
***Садриев Самат Салахович.***

Советлар Союзы Герое Садриев С.С. 1920 елның 15 январендә Лениногорск районы Иске Шөгер авылында туа.

7 сыйныфны бетергәннән соң Ярославль туку фабрикасында слесарь булып эшли.

1941 елның 22 июнен Садриев Грузиянең Кутаиси шәһәрендә каршылый.

Армиягә аны туган авылыннан 1942 елда алалар. Казанда танкистлар мәктәбен тәмамлап сержант дәрәҗәсен ала. 1942 елның ахырында Сталининградка 101 нче аерым танк бригадасына җибәрелә. Монда Америка танклары “Шерман”нар кулланыла. Курск янында да сугышы, 5 ай госпитальда ята.

Терелеп чыккач аны 47 армияга җибәрәләр. Садриевны 667 укчы пол кның автоматчылар отделениясенә командир итеп билгелиләр. 47 армия генерал Конев җитәкчелегенддәге фронт составына керә. Алар Украинаны азат итәләр, Днепрга килеп җитәләр.Хәрби бурыч : килгәч тә үк Днепр аша үтәргә һәм Киев шәһәрен алырга.

1943 елның 24 сентябрендә Днепрны кичеп чыгу башлана. Саматов җитәкчелегендәге отделение иң беренчеләрдән булып елганы кичә.

Садриевның батырлыклары:беренче батырлык – ул уңышлы елганы кичү. Ул үзеннән үзе генә килми – елганы кичкәнче сержант солдатларны өйрәтә.

Икенче батырлык – уң як ярда уңышлы һөҗүм оештыру. Бу да акыл һәм хәйлә белән уйлап эшләнә.Сержант шәхсән үзе бу көрәштә 7 гитлерчыны юк итә.

Өченче батырлык –яулап алган җирне саклау.Безнең сугышчылар Днепр аша чыккан арада алар фашистларның пулемет расчетын арттан килеп юк итә.

Дүртенче батырлык-бу 1943 елның 25 сентябрендәге каты сугыш.Ул тагын 2көн дәвам итә.Дошманның һөҗүмнәре туктаусыз дәвам итә, ләкин сугышчылар бирешмиләр.Бөтен 47нче фронт Днепр аша чыкканчы сугышны дәвам итәләр.

1943 елның 3 ноябрендә Киев өчен сугыш башлана,6 ноябрьда ул алына.

Житомир яны иде бер айлык камалыштан чыкканнан соң Садриевны Головачев җитәкчелегендәге 23 мотострелковый бригадага куялар.Шушы гаскәрләр белән ул Берлинга кадәр барып җитә.

Сандомир янында Самат Садриев командуюәий янына чакырыла .

Аны Советлар Союзы Герое Грамотасы,Ленин ордены һәм Алтын йолдыз медале белән бүләклиләр.

***Советлар Союзы Герое***
***Мурзин Ибраһим Хөсәен улы.***

Мурзин Ибраһим Хөсәен улы 1916 елда Иске Шөгер авылында туып үсә,1935 елда Иске Шөгер урта мәктәбеннең 7 классын тәмамлап,1935-1936 елларда Шөгер нефтебитум заво-дында кочегар булып эшли.

Гвардия өлкән серҗант Мурзин И.Х.үзенең сугышчан юлын Сталинград астындагы сугышлардан башлый.Ул үзенең расчеты белән күп фронтларда була.1944 елның июленнән башлап 1-Украина фронты составындагы 158-гвардия артиллерия полкында орудие командиры булып авыр сугыштан юл үтә,Одер елгасына барып җитәләр.

Совет Армиясе

***Советлар Союзы Герое***
***Халиков. Ислам Рәхим Улы.***

Ислам Рәхим улы Халиков 1918 елда Иске Шөгер авылында туа.

1937 елда заводта башта счетовод, аннары бухгалтер булып эшли. Заводта эшләгән вакытта комсорг вазифасын үти һәм ВАКСМ районында член булып тора.

1938 елда аны армиягә алалар. Ак финнарга каршы сугышта катнаша.Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән Халиков фронтта була.

1942 елның ноябрендә Ислам Халиков бригадасы Новороссийск шәһәрен геройларча саклый.

Севастопль өчен барган сугышларда Халиков бригадасы күп санлы дошман танкларына каршы

көрәшә. Халиков үзе генә ике дошман танкысын сафтан чыгара.

1944 елның августында дошман чигенә башлый.

Чигенүче дошман гаскәрләре колоннасын беренче булып разведчиклар күреп ала. Алар дошманга каршы ут ачалар. Разведчикларга ярдәмгә артиллеристлар киләләр.

Алар өчәү була: орудие командиры Ислам Халиков, Массалитин һәм Семкин. Фашистларга каршы ут ачалар. Снаряд шартлаудан Массаметин егыла, ә Халиков белән Семкин яраланалар . Фашистлар атуны көчәйтәләр.Снарядлар төягән машинага ут каба. Ләкин батыр сугышчылар чигенергә уйламыйлар.Фашистлар аларны чолгап алалар.Артиллеристлар каршы торырга хәзерләнәләр.

Фашистларның "бирелегез" дип кычкыруларына алар автоматтан атып җавап бирәләр.

Геройлар янып үләләр, ләкин дошманга бирелмиләр.

Күрсәткән батырлыгы өчен И.Р. Халиковка СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән 1945 елның 24 мартында Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

## *“Мәктәп тарихы”.*

Иске Шөгер авылында беренче мәктәп 1906 нче елда салына. Беренче укытучы *Шәкүров Гариф* була.Ул беренче-дүртенче классларны укыткан һәм арифметика, тарих, география фәннәрен кыскача аңлатырга хокук алган. Бер үк вакытта Шушма буенда өч бүлмәле мәдрәсә дә булган.Укыту икесендә дә гарәп телендә алып барылган.

1910нчы елда мәдрәсәгә караганда мәктәпкә күбрәк бала килә башлый.1912 нче елдан башлап укытучы булып *Хәйруллин Барый* эшли башлый.Мәдрәсә революциягә кадәр яши.

1910 нчы елда тау буенда алты бүлмәле мәктәп салына, аны салуда Шөгер нефтебитум заводы зур ярдәм күрсәтә.

1933-1934 нче елларда яңа мәктәп бинасы салына. 1935 нче елда урта мәктәп ачыла.

1937-1938 нче уку елларында районда беренче чыгарылыш була. Мәктәп директоры булып *Хәлимов* эшли. Сугыш башланганчы бу мәктәптә *Фәтхуллин Фатыйх, Каюмов Хәмәт, Туктаров, Дәрҗеманов Зыя, Хәеров Гариф* һәм башкалар укыта.

Мәктәп районда үзенең зыялы укытучылары һәм укучылары белән дан тота, ләкин репрессия җилләре аны да әйләнеп үтми.

## *“Сугыштан соңгы мәктәп.”*

1945 нче ел: Иске Шөгер мәктәбе үрнәк мәктәпләрдән санала, коллективы зур, бердәм була.Мәктәп директоры *Фасеев Салих Фатыхович* була.Укытучыларга бу чорда көненә 300 грамм он, өч көнгә бер арыш ипие бирәләр.

Химиядән- *Закиров Габделхак,* физку-льтурадан- *Дәүләт Миңнебаевич,* геогра-фиядән- *Ибраһимова Мәрьям Шәриповна,* рус теленнән- *Гарифуллина Сорур Валеевна,* физикадан- *Сәлимов Мөхтәр Шәрипович,* сызымнан- *Һилалов Җәүдәт Гатич,* башлангыч сыйныфларда-*Галимова Мәсгүдә Сәлимҗанов-на, Гильметдинова Асия Гильметдиновна, Таһирова Миңнур, Әһлиуллина Миңнур,* завуч-*Закирова Суфия Закировна. Салимовларны* киләсе уку елында завод мәктәбенә күчерәләр.

Укытучы агитатор да була.Кич белән педсовет, агитколлектив, идарә утырышы,авыл советы утырышы - боларның берсеннән дә калырга ярамый. 1947 нче елның җәендә мәктәпнең түбәсеннән яңгыр үтә башлагач, такта ярып такта белән ябалар.Бу ел бик кыйммәтчел ел була.Бодай оны 700сум, бу укытучының айлык хезмәт хакы.Шушы ук елны Иске Шөгер мәктәбенә химия-биология укытырга *Җәмилов Р.Ш* килә.Ул Казан кызы *Кәримова А. В.га* өйләнә һәм мәктәптә беренче тапкыр инглиз теле укытыла башлый.

***Социалистик Хезмәт Герое***
***Зиннәт Шарифуллин.***

Иске Шөгер мәктәбендә укыганда ук тыйнак, игътибарлы һәм тырыш булуы белән аерылып тора.. Бөек Ватан сугышында бронетанк командиры, лейтенант була. Зиннәт Шарифуллин 1950нче елның апреленнән Шөгердәге беренче скважиналарда дизелист булып эшли башлый. 1952нче елдан –оператор.Аның җитәкчелегендә операторлар скважиналарны электролаштыралар, җиһазлыйлар. Барлык 35 скважина өзлексез контрольда торсын өчен яңа эш алымнары кертә. Зиннәт Шарифуллин үзе дә һәр елны 4-5 радионализация тәкъдимнәре кертә. Аның тормыш кагыйдәсе:” Нефтьче скважиналар өчен кирәк булган бөтен һөнәрне белергә тиеш”. Ул тракторчылык, электрик, машинистлык, слесарь-ремонтчылык һөнәрләрен үзләштерә. Үзенең бай тәҗрибәсен яшьләргә бик теләп өйрәтә. Ул-актив җәмәгать эшчесе.Хәзерге вакытта ул лаеклы ялда. Әлмәт шәһәрендә яши.

## *Социалистик Хезмәт Герое Миңнекәев Мәсгут .*

Мәсгут Миңнекәев 1930 нчы елның 11 нче апрелендә Шөгер районы Яңа Елховой авылында туа.

1950 нче елда Иске Шөгер урта мәктәбен тәмамлый.

1956 нчы елда Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайтка.

Миңнебай Газ эшкәртү заводында егерме ел оператор булып эшли башлый.

Читтән торып Лениногорск нефть техникумын тәмамлый. Гади эшчедән инженер дәрәҗәсенә кадәр үсә.

Хезмәттә күрсәткән батырлыклары өчен медальләр һәм күп төрле грамоталар белән бүләкләнә.

1966 нчы елны мактаулы исемгә- Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек була.

Хәзерге вакытта ул лаеклы ялда булуына карамастан, җәмгыять эшендә актив катнаша.

Бүгенге көндә Әлмәт шәһәрендә яши.

## *Социалистик Хезмәт Герое*
## *Шәрәфетдинов Фәсхетдин .*

Шәрәфетдинов Фәсхетдин Шөгер мәктәбен 1941 нче елда тәмамлый.

Шөгердә нефтеразведкада эшли башлый, ләкин озак эшләргә туры килми.

Ул үзе теләп Бөек Ватан сугышына китә һәм 1946 нчы елда гына демобилизацияләнеп туган якларына кайта.

Фронтта күрсәткән батырлыклары өчен “Кызыл йолдыз” ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң, элеккеге эше – нефтеразведкада эшли башлый. Башта эшче, аннары верховой, бурильщик, инструктор була. 1949 нчы елдан ул буровой мастер булып эшли.

Аның бригадасы 140 лап тирән разведка скваинасы бораулады.

Бу бригада 1963 нче елдан бирле “Коммунистик хезмәт бригадасы” исемен йөртә.

Лаеклы ялга чыккач та ул җәмәгать эшләрендә актив катнаша.

## *Касыйм Тәхау.*

Касыйм Тәхау- Тәхаутдинов Касыйм Нури улы Лениногорск районының Тукмак авылында дөньяга килгән.

9 нчы класста укыган җиреннән 17 яшьлек егет хәрби хезмәткә алына. Дөресрәге, шул елларның патриотик дулкынында үз теләге белән Ватанны сакларга ашкына. Яшь егетне Көнчыгыш чикләргә озаталар. Ихтимал, анда да хәтәрлек җитәрлек булгандыр.

1947 елны Иркутск шәһәрендәге хәрби авиация механиклары мәктәбен, аннары Казан хәрби авиация техник училищесын төгәлли. Техник әзерлекле белгечне моторларга һәм самолетларга хезмәт күрсәтү башлыгы итеп билгелиләр. 14 ел чамасы хәрби хезмәттә булганнан соң Касыйм Тәхаутдинов кинәт кенә язмышында текә борылыш, очучылар теле белән әйткәндә, вираж ясый.

Виражның асыл сәбәбе, бәлки, болайдыр: инде хәрби погоннарга шактый ияләшкән егет бәхетен Хәрби академиядә сынап карарга ниятли. Ләкин татар егетенә чират җитми, төрле сәбәпләр табылып кына тора. Берәү булса, майор погоннарына тиенгәнче, хәрби хезмәттә һаман йөрер иде, ләкин Касыйм Тәхаутдиновның безгә шактый таныш тәвәккәл холкы үзенекен итә. Янәсе, алаймы, чират җитмиме, сөйгән Казанымда миңа һәрвакыт урын табылыр, ди дә Казанына кайтып китә.

1956 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүле-генә читтән торып укырга керә. 1962 елдан 1990 елга кадәр Татарстанның иң өлкән, иң абруйлы газетасында- хәзерге “Ватаным Татарстан” редакциясендә әдәби хезмәткәр, өлкән әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире, җаваплы секретарь урынбасары вазифаларын башкара. Әйтергә кирәк, штыкны каләмгә алыштыр-ганына беркайчан да үкенми.

60 яшен тутыргач пенсиягә киткәндер, дисезме? Юк.1995 елга кадәр “Татарстан хәбәрләре” газетасында эшләде. Хезмәтенә күрә хөрмәтен дә казанды. Аның Татарстан Республикасының төрле оешмалары тарафыннан бирелгән Мактау язучылары бихисап.”Атказанган мәдәният хезмәткәре” дигән исеме бар.Журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге премиясе лауреаты да ул. Бөек Ватан сугышы чорында алган медальләре исә Җиңү көнендә күкрәген калкан кебек каплый.

Бөек Җиңүне бәйрәм иткән көннәрдә “Мәдәни җомга” газетасында Касыйм Тәхауның 1943 елда армиягә китеп барганда язган шигырьләр циклы басылып чыккан иде.

Бөек Ватан сугышы елларында аңа илнең көнчыгыш чикләрен япон самурайларыннан саклауда катнашырга туры килде. Баш очыбызда дошман туплары шартлап тормаса да, безнең солдатлар бик тә авыр шартларда хезмәт иттеләр.Үлем –китемнәр була торгач, ачлыкның да

нәрсә икәнен татыганнар, башка җәфаларны да кичергәннәр.

1945 елның август аенда аларның 94 нче укчы дивизия, башкалар белән бергә, көчле ташкын булып, Квантун армиясенә ташланды.Сентябрь башында самурайлар җиңелеп, кулларын күтәрергә мәҗбүр булдылар.

Касыйм Тәхау утлы елларда ике дистә чамасы шигырь язган.Ул чакта солдат кешегә шигырь язу турында уйланып йөрергә мөмкинлек бик тә аз булган.

Шигърият аның белән гомер буе янәшә яшәгән. Аның шигырьләренә хал-кыбызның куренекле композиторлары Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин, Александр Ключарев,Заһит Хәбибуллин, Сара Садыйкова, Әнвәр Бакиров җырлар яздылар.Татарстан китап нәшриятында биш-алты китабы дөнья күрде.Алар арасында мари, Питрәч, Лаеш урманнарында таяк һәм кәрҗин тотып тын ауда йөргәндә табылган, җиләкләргә, гөмбәләргә ияреп өйгә кайткан нәни хикәяләр-дән торган җыентык та, балалар өчен язылган шигырьләрдән тупланган “Куян күчтәнәче” китабы да бар.Газетабыз укучылары Касыйм Тәхауны “Табигать мизгелләре” сәхифхлхре буенча бик яхшы хәтерлиләр булыр. Өлкәнәеп, шактый тәҗрибә туплагач, булмаган сакалына шактый акыл урагач, ул безне “Гыйбрәтле гыйбарәләр” белән гаҗәпләндерә башлады.

***Фасееев Камиль Фатыхович.***

Танылган дәүләт эшлеклесе һәм галим, элеккеге ТАССР Югары Совет Президиумы Рәисе.

К.Ф.Фасеев Самара губернасы Бөгелмә уезды Яңа Печмән волосте Тимәш авылында туа. Үзенең хезмәт биографиясен ТАССРның Шөгер районында укытучы булып 1936 елда башлый. 1939-1943 елларда ВЛКСМның Шөгер райкомы секретаре, ТАССРның Яңа Печмән райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире. 1953 елда ЦК КПССның иҗтимагый фәннәр Академиясен тәмамлагач, фән һәм мәдәният бүлеге мөдире булып эшләгән, ТАССР Югары Советы Президиумы Рәисе. РСФСР һәм ТАССР Югары Советларына депутат итеп сайлана. 1959-1963 елларда РСФСР Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары була.

1960 елдан Камил Фатыхович Фасеев фәнни һәм педагогик эшчәнлек белән актив шөгелләнә башлый: өлкән фәнни хезмәткәр, СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, соңрак- доцент, профессор, В.И.Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының фәнни коммунизм кафедрасы рәисе. Соңгы көннәренә кадәр Казан дәүләт университеты белән бәйләнгән, профессор-консультант булып эшләгән, философия фәннәре докторы.Ике “Почет Билгесе” ордены, өч медаль белән бүләкләнгән. “ТАССРның атказанган фән эшлеклесе”.

***Роза Сәет кызы Хафизова.***

1929 елның 6 февралендә Татарстан АССРның Бөгелмә шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туган.Татарстанның хәзерге Лениногорск районы Сарабиккол авылында җиде класс һәм Иске Шөгер урта мәктәбендә ун класс тәмамлаганнан соң, 1947-1951 елларда В.И. Ульянов- Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә югары белем ала. 1952-1960 елларда ул “Татарстан яшьләре”, Чистай өлкә газетасында,Казандагы күптиражлы “Төзелештә” газета редакциясендә әдәби хезмәткәр, КПСС Өлкә комитеты каршындагы Партия тарихы институтында фәнни хезмәткәр һәм Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли. 1962 елда “Ялкын” журналының баш редакторы итеп билгеләнә. 1974 елда Татарстан АССРның, 1983 елда РСФСРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирелде. Истәлекләр: “Бөгелмә каласында туганмын. Әмма туган җирем итеп өч төбәкне саныйм: беренчесе- әтием, Хафизов Мирсәет Хәмзә улы туып-үскән Бәйрәкә авылы (Ютазы районы),икенчесе- әнием Мәгъмүрә туып-үскән Сарабиккол авылы. Балачагым гүзәл табигатьле шушы авылда узды. Өченчесе-мин дөньягкилгән Бөгелмә каласы. Биредә тик ике яшькә кадәр генә яшәгәнмен. Әтине Шөгер районына эшкә күчергәннәр. 17 яшемә хәтле шушында яшәдек. Җидееллык мәктәпне Сарабикколда тәмамладым.”

***Индус Таһиров.***

Индус Ризак улы Таһиров 1936 елда Иске Шөгер авылында туа. Индус-интеллигент гаиләсеннән чыккан бала.

Аның әтисе- Шөгер кешесе. Колхоз рәисе, авылы Советы башлыгы булган. Әнисе-Әминә апа гомере буе укытучы. Өч ир бала табып, шуларга сөенеп-куанып, якты өметләр белән яшәп ятканда,сугыш атлы бәладән башы чыкмаган СССРга янә шул афәт ябырыла. Беркемне дә урап үтмәгән, барлык ир-атны кырып-себереп үз казанына кубарып алып кереп киткән Ватан сугышы. Активист Ризак ага, аңлашылса кирәк, беренче көннәрдә үк сафка алына. Аны яманаты чыккан Суслангерга әзерлек узарга җибәрәләр.

Сугыш вакытында аны Чыршылы авылына мәктәп директоры итеп җибәрәләр. Сугыш тәгәлләнгәч,тагын Шөгергә. Индус башлангыч белемне татар мәктәбендә ала. Аннары рус теле мәктәпкә күчәргә туры килә. Яшәү шартлары тәмам хөртиләнгән, җиңелрәк булмасмы дип, Әминә апа өч улы белән Әлмәткә, туганнары янына кайта, мәгариф бүлегенә инспектор булып эшкә керә һәм пенсиягә чыкканчы шунда хезмәт итә. Бала чакта ук Индуска китап җене кагыла. Уртамәктәпне уңышлы төгәлләп, армиягә эләккәч тә буш вакытны буш итми, китаптан аерылмый. Хезмәт итеп кайткач, Индус Казан дәүләт университетының тарих факультетына имтихан тота.

Шулай, 1963 елдан башлап Индус Ризакович язмышы университет белән бәйле. Актив студент, лидер, факультетның комсомол комитеты секретаре,һәм, әлбәттә инде, фән. Аның гыйльми җитәкчесе, каферда мөдире И. Ионенко аспирантурага керергә тәгъдим итә. Аспирантурада чагында ук ул И.Ионенко белән берлектә, Казанда Октябрь революциясе тарихы турында зур китап иҗат итә, вакытлы матбугатта күпсанлы мәкаләләр бастыра. Кандидатлык диссертациясе яклаганнан соң- кафедра: ассистент, докторлык диссертациясе яклау, профессор, кафедра мөдире, декан.
Демократия җилләре кузгалу белән Индус Ризаковичның яңа сәләт-талантлары ачылды. Энесе Энгель Ризакович аның юлыннан китте. Хәзер ул киң җәмәгатьчелеккә билгеле галим,кафедра мөдире, улы-фәннәр кандидаты. Кыскасы, галимнәр гаиләсе.

Советлар Союзы Герое

Мурзин Ибраһим Хөсәен улы.

Мурзин Ибраһим Хөсәен улы 1916 елда Иске Шөгер авылында туып үсә,1935 елда Иске Шөгер урта мәктәбеннең 7 классын тәмамлап,1935-1936 елларда Шөгер нефтебитум заво-дында кочегар булып эшли.

Гвардия өлкән серҗант Мурзин И.Х.үзенең сугышчан юлын Сталинград астындагы сугышлардан башлый.Ул үзенең расчеты белән күп фронтларда була.1944 елның июленнән башлап 1-Украина фронты составындагы 158-гвардия артиллерия полкында орудие командиры булып авыр сугыштан юл үтә,Одер елгасына барып җитәләр.

***Социалистик Хезмәт Герое***
***Зиннәт Шарифуллин.***

Иске Шөгер мәктәбендә укыганда ук тыйнак, игътибарлы һәм тырыш булуы белән аерылып тора.. Бөек Ватан сугышында бронетанк командиры, лейтенант була. Зиннәт Шарифуллин 1950нче елның апреленнән Шөгердәге беренче скважиналарда дизелист булып эшли башлый. 1952нче елдан –оператор.Аның җитәкчелегендә операторлар скважиналарны электролаштыралар, җиһазлыйлар. Барлык 35 скважина өзлексез контрольда торсын өчен яңа эш алымнары кертә. Зиннәт Шарифуллин үзе дә һәр елны 4-5 радионализация тәкъдимнәре кертә. Аның тормыш кагыйдәсе:" Нефтьче скважиналар өчен кирәк булган бөтен һөнәрне белергә тиеш". Ул тракторчылык, электрик, машинистлык, слесарь-ремонтчылык һөнәрләрен үзләштерә. Үзенең бай тәҗрибәсен яшьләргә бик теләп өйрәтә. Ул-актив җәмәгать эшчесе.Хәзерге вакытта ул лаеклы ялда. Әлмәт шәһәрендә яши.

“***Мәктәп тарихы”.***

Иске Шөгер авылында беренче мәктәп 1906 нче елда салына. Беренче укытучы *Шәкүров Гариф* була.Ул беренче-дүртенче классларны укыткан һәм арифметика, тарих, география фәннәрен кыскача аңлатырга хокук алган. Бер үк вакытта Шушма буенда өч бүлмәле мәдрәсә дә булган.Укыту икесендә дә гарәп телендә алып барылган.

1910нчы елда мәдрәсәгә караганда мәктәпкә күбрәк бала килә башлый.1912 нче елдан башлап укытучы булып *Хәйруллин Барый* эшли башлый.Мәдрәсә революциягә кадәр яши.

1910 нчы елда тау буенда алты бүлмәле мәктәп салына, аны салуда Шөгер нефтебитум заводы зур ярдәм күрсәтә.

1933-1934 нче елларда яңа мәктәп бинасы салына. 1935 нче елда урта мәктәп ачыла.

1937-1938 нче уку елларында районда беренче чыгарылыш була. Мәктәп директоры булып *Хәлимов* эшли. Сугыш башланганчы бу мәктәптә *Фәтхуллин Фатыйх, Каюмов Хәмәт, Туктаров, Дәрҗеманов Зыя, Хәеров Гариф* һәм башкалар укыта.

Мәктәп районда үзенең зыялы укытучылары һәм укучылары белән дан тота, ләкин репрессия җилләре аны да әйләнеп үтми.

Первый учитель



ева Г.З Шукуров. Снимок сделан в Бугульме в 1906








5-32/5


5-32/3







ЗАВУЧ

**Член-корреспондент Академии наук Республики Татарстан**

**Даутов Гали Юнусович**



Родился в 1931 году. Физик-энергетик. Доктор технических наук (1969), профессор, член-корреспондент АН РТ (1992). Заслуженный деятель науки и техники Российской Федерации и Республики Татарстан. Профессор кафедры общей физики Казанского государственного технического университета им. А.Н.Туполева.

Окончил с отличием Казанский авиационный институт. Работал конструктором НИИ оборонной промышленности, главным механиком в тресте “Лениногорскнефтестрой”, заведующим лабораторией Института теоретической и прикладной механики Сибирского отделения АН СССР, заведующим кафедрой общей физики КАИ.

Г.Ю.Даутов разработал аналитическую теорию электрической дуги, стабилизированной в канале с потоком газа, которая составляет теперь основу инженерных расчетов генераторов низкотемпературной плазмы – плазмотронов. Созданные при его участии мощные серийные

плазмотроны внедрены на многих предприятиях и в научно-исследовательских учреждениях.

Г.Ю.Даутов – автор монографий “Плазмотроны со стабилизированными электрическими дугами”, “Моделирование и методы расчета физико-химических процессов в низкотемпературной плазме”, изданных в Москве и Киеве, а также учебного пособия “Электродуговые и высокочастотные плазмотроны в химико-металлургических процессах”, выпущенного киевским издательством “Высшая школа”. В монографии “Генераторы неравновесной газоразрядной плазмы” им обобщены результаты исследований в этой области за последние годы. Ученым опубликовано двести восемьдесят два научных труда, в том числе четыре монографии, два учебника и два учебных пособия. По его инициативе в КАИ была создана лаборатория низкотемпературной плазмы.

Г.Ю.Даутов создал и возглавил научную школу по физике и технике низкотемпературной плазмы.

Им подготовлено более пятидесяти кандидатов и восемь докторов наук. Имеет сорок шесть патентов и авторских свидетельств на изобретения. Среди них – электродуговой плазмотрон для напыления порошковых материалов, способ химико-термической обработки металлов и сплавов, способ очистки поверхности тепловой трубы и устройство для его осуществления.

Г.Ю.Даутов возглавлял секцию физики и техники плазмы при Татарском республиканском совете научно-промышленного общества, является руководителем научного направления “Плазменная обработка поверхностей деталей авиационной техники”.

Научная программа исследований посвящена разработке теории преобразований энергии в плазме и созданию высокоэффективных плазмотронов и ионно-плазменных технологий – физике низкотемпературной плазмы и плазменной технологии.

Награжден семью медалями, в том числе “За доблестный труд в годы Великой Отечественной войны 1941–1945” и имени Ю.А.Гагарина.

Тел.: (843) 231-02-23
Факс: (843) 231-02-24
E-mail: physics@physics.kstu-kai.ru

**Действительный член Академии наук Республики Татарстан**

**Тагиров Индус Ризакович**



Родился в 1936 г. Историк. Доктор исторических наук, профессор, действительный член АН РТ. Заведующий кафедрой отечественной истории, декан исторического факультета КГУ. Заслуженный деятель

науки Российской Федерации и Республики Татарстан.

Окончил Казанский государственный университет и аспирантуру при кафедре истории СССР, с 1967 г. – кандидат, с 1979 г. – доктор исторических наук. С 1966 г. работал на кафедре отечественной истории КГУ ассистентом, доцентом, профессором.

Основные научные исследования И.Р.Тагирова проведены по истории революционных, национальных движений в России, национально-государственному строительству в Татарстане. Его восемь монографий, более ста научных публикаций получили высокую оценку во многих странах, в том числе в США, Англии, Турции, Японии, Франции.

Труды И.Р.Тагирова по истории Татарстана и татарского народа в XX веке, “Очерки истории национальной государственности татарского народа и Татарстана” впервые представили цельно историю национальной государственности татарского народа, охватывающую период в более чем три тысячи лет.

И.Р.Тагировым исследованы такие крупные исторические темы, как “Казань в 1917 году”, “Солдатские массы в Октябрьской революции”, “К истории национально-демократических организаций”, “К вопросу о многовариантности исторического процесса”, “Диалектика соотношения характера власти и способов решения национального вопроса в России в 1917 году”, “На

путях научного мировоззрения”, “История, проблемы, уроки” (в соавторстве).

В первых своих работах: “К вопросу об особенностях восстания в Казани”, “Казанский октябрь в литературе 20-х годов”, “От февраля – к октябрю” (в соавторстве) И.Р.Тагиров одним из первых в исторической науке определил место и роль национального фактора в общественном развитии страны.

Одна из его ранних работ касалась малоизученного вопроса о взаимоотношениях казанских большевиков с левым крылом мелкобуржуазной демократии.

И.Р.Тагиров является председателем специализированного совета по защите докторских и кандидатских диссертаций по историческим наукам при Казанском государственном университете. Под его научным руководством подготовлено более двадцати кандидатских диссертаций, он был научным консультантом пяти докторантов.

В исторических исследованиях И.Р.Тагирова раскрыты идеи и общественная, государственная деятельность Столыпина, Султан-Галиева – крупных политических деятелей прошлого. Им опубликованы статьи по истории “Идель-Урала”, Башкирской и Татарской республик.

И.Р.Тагиров участвовал с докладом на VII Международном конгрессе преподавателей русского языка и литературы, состоявшемся в Москве в 1990

году. Является председателем исполнительного комитета Всемирного Конгресса татар.

Тел.: (843) 231-54-47
E-mail: kazanmars@rambler.ru

## ***Беренче укытучы – Гариф Шәкүров.***

Гариф Зиатдинович Шөгеров Яңа Шөгер авылында иң белемле кеше буларак таныла. Ул Казанда белем алган, ә аның абыйсы Новгородта рус теле укыткан. Гариф Зиатдинович авылда иң беренче укытучы булган, ул 1916 нчы елда үзенең өендә мәктәп ача, ә укыта башлаган була ул 1908 нче елда. Аның хатыны Фахирә Корбангалиевна танылган татар мәгърифәтчесе Риза Фәхретдиннең туганы була, ул кызларны укыта. Алар балаларны гарәп телендә укырга, язарга өйрәтәләр, география, дин тарихы, татар тел буенча дәресләр алып баралар, ә кызлар шулай ук кул хезмәтенә, тегәргә һәм чигәргә өйрәнә.

Шөгеровлар Риза Фәхретдиннең :"Бала чакта алган тәрбияне бөтен дөнья халыклары да үзгәртә алмый" дигән сүзләрне искә алып эшлиләр. Алар белем биргән балаларның күбесе Бөек Ватан сугышыннан кире кайтмыйлар, ә кайберләре танылган кешеләргә әйләнә. Шуны да онытмаска кирәк, әгәр дә алар булмаса, авыл халкына балаларын Бөгелмәгә илтергә туры килер иде, ә болай ата-аналарга тынычрак- балалар өйдә, кирәк чакта ярдәм дә итә алалар. Шөгеровларның абруе авылда бик югары була, аларны ихтирам итәләр. Гариф Зиатдиновичка ихтирам зур булуын түбәндәге факт та раслый- авылда мәчет төзелгәч, аңа Коръәнне яхшы белүче кеше буларак, мулла булырга тәкъдим итәләр. 30 нчы елларда авылда кулакларга каршы көрәш башлана. Гариф

Зиатдинович гаиләсе зур була- улы һәм дүрт кызы, шуңа хуҗалыкта ат, сыер, биш сарык була. Боларның барысын да конфискациялиләр, өеннән куып чыгаралар, үзен кулга алалар. Фахирә Корбангалиевна ирен Бөгелмә төрмәсенә озата. Гаиләгә кая барырга? Хәбиров Минсәеф абзый һәм Әсма апа, үзләренең биш балалары булуга карамастан, Шөгеровлар гаиләсен дә сыендыралар (бу гамәл бик куркыныч санала, чөнки моның өчен Себергә дә җибәрергә мөмкин). Көзен Шөгеровлар яшерен рәвештә Бөгелмәгә, ә аннан Сулы авылына күчә. Гариф Шөгеров та шунда кайта, ләкин гаиләгә тыныч тормышта өч ел гына яшәргә туры килә. “Халык дошманнарын” эзләү башлангач, Гариф Зиатдинович Урта Азиягә китә, бер елдан әйләнеп кайта һәм алар Яңа Шөгер авылына кире кайталар. Шактый вакыт алар мунчада яшиләр, Гариф Шөгеров колхозда тырышып эшли, 1945 нче елда медаль белән бүләкләнә, лаеклы ялга китә, ә 1965 нче елда ул үлә.

Аның кызы Раушания Гарифовна сугыш елларында иптәш кызлары белән 1943 нче елда Шөгер нефть ятмасын ачуда катнаша, сугыштан соң Советлар Союзы Герое Самат Садриевка кияүгә чыга. Абыйсы һәм апалары шулай ук нефть өлкәсендә эшлиләр.

*Зиангирова Миннур Зиангировна.*

1917 елны Лениногорск районы Сугышлы авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа.1926-29 елларда Сугышлы башлангыч мәктәбендә укый.

1929-1933 елларда-Түбән Чыршылы җидееллык мәктәбендә белем ала. 1933-1936 елларда Бөгелмә мәктәп-педтехникумында укый. 1937-1941 елларда читтән торып КДПИ тәмамлый һәм татар теле һәм әдәбияте укытучысы белгечлеге ала. 1936-1940 елларда татар теле һәм әдәбиятен Федотовка,Урдалы,Куакбаш мәктәпләрендә укыта. 1940-1942 елларда Федотовка урта мәктәбе директоры була.1942 елның августына үзе теләп фронтка китә.Санинструктор,писарь булып Харьков стрелковый дивизиясенең Сталинград,Белгород, Харьков,Полтава фронтларында көрәшә. Батырлыклары,хәрби шартларда заданиеләрне төгәл үтәгәне өчен “За боевые заслуги”,”За оборону Сталинграда” медальләре белән,”Красная звезда” ордены белән бүләкләнә. 1944 елда өлкән сержант дәрәҗәсендә контузиядән соң туган якларына кайта. 1944 ел сентябрь-декабрендә ВКП(б)ның Шөгер райкомында инструктор булып эшли. 1944 елның декабрендә-1945 елның июнендә республика партия мәктәбендә укый. Аннан 1945 елда Шөгер районы РОНОсына заведующий итеп билгеләнә,1947 елга кадәр эшли. 1947-1967 елларда Иске Шөгер мәктәбендә укытучы булып эшли. 1967-1974 елларда оештыручы булып эшли.“Халык мәгарифе

отличнигы” билгесе белән бүләкләнә; РСФСРның атказанган укытучысы.

“***Шөгер авылының барлыкка килүе.***”

Шөгер урнашкан урын башта урман булган.Алар башкорт биләмәләре булып саналган.

1615-1620 нче еллар тирәсендә Шөгер урнашкан җиргә беренче кешеләр килеп урнашкан.Күчеп килүчеләр арасында баш-кортлар, мишәрләр, типтәрләр булган. Күчеп килү сәбәпләре булып гади халыкның йөкләмәләре арту һәм салымнар күбәю тора.Моннан тыш рус булмаган халыкларга карата милли һәм дини басым көчәя. Хакимият һәм христиан руханилары көчләп чукындыру сәясәте үткәрәләр.

Халык саны арткан саен,урманнар киселә һәм төпләп яндырыла бара , чәчүлек җир-ләргә әйләнә. 1630 нчы елларда Шөгергә күчмә ногайлар һөҗүм итә.17 нче гасырның ахырына Шөгер рус биләмәләре составыны керә.19 нчы гасырның урталарына Шөгергә рус чиновнигы Ященко килә.Ул Шөгер халкына бу җирләрне дәүләтнеке итмичә, үзенә салым түләргә куша.Шөгер халкы моңа риза була.Йорт башына бер сум түләп тора , дәүләт тә бу урыннардагы халыкларга күп төрле налоглар сала башлый. 19 нчы гасырның ахырына аларның саны арта.

1904 нче елда рус-япон сугышы башлана.Шөгердән дә ир-атлар сугышка китә.

***“Авыл тарихын өйрәнүне башлап йөрүчеләр.”***

Шөгер авылы тарихын киң күләмдә искә төшерүче, бу тарихны борынгы язмалардан эзләп төзешүче, Иске Шөгер авылыннан *Сәлимов Габдулла* ага була.Сәлимов Габдулла 1893нче елда Самара губернасы, Бөгелмә өязе, Спиридон волосте, Иске Шөгер авылында туган.Әтисе урта хәлле крестьян булган.1931нче елда колхозга кергән. Колхозда озак еллар яшелчә бакчасында эшләгән. 1914-1915нче елларда беренче бөтендөнья сугышында катнашкан. 1917 нче елда Волгоград шәһәрендә булган. Анда 191нче запас полкта торган. Гражданнар сугышында катнашкан.1920нче елда ак полякларга каршы көрәш алып барган.

Иске Шөгер авылы тарихын тирәнтен белүче, аны туплап яшь буынга җиткерүчеләрнең тагын берсе *Хәбиров Сәгыйть* абый. Ул 1932нче елда туа. Әтисе районда беренче ашханәнең остасы Минсәеф ага, әнисе “Партизан” колхозы алдынгысы Бибиәсма апа. Хәбиров С. Иске Шөгер мәктәбен гел яхшы билгеләренә генә тәмамлый. Бөгелмә укытучылар институтын тәмамлагач Себердә мәктәп директоры булып эшли.Иске Шөгер мәктәбенә 28 еллык эш тәҗрибәсе белән кайта. Монда 12 ел эшләп, 1992нче елда пенсиягә чыга. Шуннан соң да әле 6 ел мәктәптә эшли.

## *“Зыялылар фаҗигасе.”*

1920-1930нчы елларның канлы вакыйгалары Иске Шөгер авылына да килеп җитә. Ил буйлап репрессияләр дулкыны үтә. ГУЛАГ лагерьлары аша 40 меңләп кеше үтә, шулар арасында безнең төбәк кешеләре дә була.

Иске Шөгер авылында танылган *Шәкуров-лар*ның борынгыдан килгән династиясе гый-брәтле.

Акмөхәммәт
Колмөхәммәт
Бикмөхәммәт
Хәнәфия
Гәбдерәшит
Мусанетдин

Зыятдин Шиһабетдин

Әбнәгыйм Исмагыйл Гариф Ризатдин Тәүфыйк

Исхак

Зыятдин хәзрәтнең өч улы мулла булалар:Исмагыйл 1939 нчы елда Шөгердә авы-рып вафат була, Гариф таланып сөргенгә озатыла, Ризатдин кулга алынып Арча төрмәсендә үлә.

Бүгенге көндә Шөгер үзәк мәчетендә сөргенгә сөрелеп юкка чыккан тагын бер Шөгер мулласы Җиһаншаның оныгы Дамир имамлык итә. Иске Шәгер мәктәбеннән *Туктаров*, *Куропаткин*, *Алтынбаев*ларны да төнге бердә алып китеп юк итәләр.

## *“Гражданнар сугышы”.*

1918 нче елда сугыш башлана.Чехлар Шөгерне узалар, ләкин сугыш хәрәкәтләре алып барылмый. Кызыл Армия аларны Бөгелмәгә таба куа.

1919 нчы елда Колчак гаскәрләренең бер өлеше дә Шөгер аша уза. Алты крестьянны ат җиктереп Чирмешәнгә илттерәләр, анда күпер ватык булганлыктан, шуны төзәтергә кушалар. Сәлимов Габдулла качып кайта. Гражданнар сугышына Шөгердән катнашучылар:

1.Ахметзянов Газимҗан
2.Ахмезянов Сәлим
3.Бадертдинов Фәсхетдин
4.Биктаһиров Хабибрахман
5.Борханов Моратша
6.Вафин Насыйрҗан
7.ГабделгалиевТәүфыйк
8.Гаделшин Мөбәракша
9.Галимов Сәлимҗан
10.Гараев Гата
11.Ганиев Хаматша
12.Гиматдинов Гәрәй
13.Гиматдинов Кыям
14.Зайнагутдинов Хәниф
15.Зарипов Гәрәй
16.Латыпов Хафиз
17.Минахметов Габделхак
18.Мифтахов Фаттах
19.Насертдинов Галялетдин
20.Насертдинов Хафиз
21.Насыйрҗанов Шакир
22.Низамов Ризатдин
23.Садриев Кыям
24.Салимов Габдулла
25.Салахов Сахап
26.Сөләйманов Локман
27.Фатхутдинов Гариф
28.Халимов Хайрулла
29.Халиков Рәхим
30.Халиуллин Гиззатулла
31.Хаеров Хәниф
32.Хәйретдинов Хәйбри
33.Хасанов Минәхмәт
34.Шакирҗанов Рәхимҗан
35.Шамсуллин Галиулла
36.Шамсуллин Хәбибулла
37.Шарафетдинов Мөхетдин

## *“ Сәнәкчеләр восстаниесе.”*

1920 нче елның 8 нче февралендә В.И Ленин телеграмма суга. Ул анда Мәскәү, Петроград, Көнбатыш һәм башка фронтларда икмәк запасы 3-4 көнлек кенә калганы һәм ул икмәкне Казан губернасыннан җыю кирәклеген әйтә. Һәм азык-төлек отрядлары сугышчылары бу боерыкны наган белән үтәргә керешәләр. Шулай итеп, сәнәкчеләр восстаниесен про-дотряд солдатларының каты җәзалар белән соңгы икмәген тартып алуга каршы җәелеп киткән хәрәкәт итеп карарга кирәк.

Безнең якларда восстаниенең штабы Карабашта һәм Куакбашта була. Әмма вос-стание бу ике авыл белән генә чикләнми. Сәнәкчеләр Түбән һәм Югары Чыршылы, Иске Шөгер , Иштерәк, Сугышлы һәм башка авылларда “эзләрен” калдыралар.Һәр авылда диярлек, дистәләгән гади халык, укытучылар, хәтта алдынгы карашлы муллалар кырыла.

1920 нче елда сәнәкчеләр нык, калын тавышлар белән дога кылып Шөгергә килеп җитәләр.Совет власте яклылар белән атыш башлана.Комендантлары *Зәйдуллин Сөнгатул-ла* була.Керкәледән кайтып өлгергән Кызыл Армия 28 сәнәкчене кулга ала һәм атып үтерә.Тирә-як авыллардан туганнары төнлә генә мәетләрне алып китәләр.

## *“Культура революциясе”.*

Яңа хакимият коммунистик аңлы яңа кеше тәрбияләүгә алына.Гасырлар буе укымышлы татар халкы 1920-1930 нчы елларда белем-сезгә әйләнә,чөнки гарәп имлясыннан латинга күчү башлана.

Авылда дингә һәм мәдәнияткә каршы көрәш башлана, басма һәм кулъязма китаплар авыл мичләрендә юкка чыга.

1937 нче елда авылдагы өч мәчетнең манарасы бер үк көнне киселә.Бер мәчет мәктәп итеп үзгәртелә, икенчесе клуб, ә өченчесе балалар бакчасына әйләнә. Авылда бары тик бер мәчет кала.

1933-1934 нче елларда яңа мәктәп төзелә.

1937-1938 нче елларда аның беренче чыгарылышы була.

Культура революциясе нәтиҗәсендә авыл-да укымышлылыгы ягыннан халыкта берничә катлам барлыкка килә:гарәпчә генә укый-яза белүче, латинча гына белүче, кириллицаны гына белүче һәм өч алфавитны да белүче кешеләр катламнары. Китапсыз, зыялы укы-тучыларсыз калдырылган халыкны начар гадәтләрдән тыю механизмы җимерелә, рухи бушлык барлыкка килә. Бу бушлыкны комму-нистик идеология, балалар арасында пионер, комсомол оешмалары барлыкка килү тутыра.

***“Пионер оешмасы тарихы”.***

1922нче елның 19 нчы маенда комсомолның икенче Бөтенроссия конференциясе илебезнең барлык шәһәр һәм авылларында пионер отрядлары оештыру турында карар чыгара.

Шөгердә пионер оешмасы 1930 нчы еллар тирәсендә барлыкка килә. 4нче класс укучыларын пионерга кабул итәләр. Алар башта гариза язалар, тантаналы вәгъдә ятлыйлар. Ул чорда Шөгердә 4 еллык кына мәктәп була, бөтен укучыларны линейкага җыялар һәм кызыл байрак янында тантаналы вәгъдә биреп пионерга керәләр.

Шөгер авылы өстендә беренче тапкыр быр-гы, барабан тавышлары яңгырый.Пионерлар колонна белән җырлап авыл әйләнәләр.

Шөгер мәктәбенең беренче пионерлары:*Салахова Әминә, Кашапова Мөсәвәрә, Ямалтдинов Җәмил , Мифтахов Якунян, Әһлиуллина Миңнури.*

Тора-бара пионерларның сафлары арта. Алар авыл халкы алдында кон цертлар
куялар, стена газеталары чыгаралар, лозунглар язалар һәм башка файдалы эшләр белән шөгелләнәләр.

Мәктәп пионерларга формалар тектерә, соңрак алар кибеткә кайта башлыйлар.Беренче пионерлар отрядлары оештыручылар: *Роза Фатхуллина,Зөһрә Хәсәнова, Шафик Фатхуллин.*

## *“Мәктәп тарихы”.*

Иске Шөгер авылында беренче мәктәп 1908 нче елда салына. Беренче укытучы *Шәкүров Гариф* була.Ул беренче-дүртенче классларны укыткан һәм арифметика, тарих, география фәннәрен кыскача аңлатырга хокук алган. Бер үк вакытта Шушма буенда өч бүлмәле мәдрәсә дә булган.Укыту икесендә дә гарәп телендә алып барылган.

1910нчы елда мәдрәсәгә караганда мәктәпкә күбрәк бала килә башлый.1912 нче елдан башлап укытучы булып *Хәйруллин Барый* эшли башлый.Мәдрәсә революциягә кадәр яши.

1910 нчы елда тау буенда алты бүлмәле мәктәп салына, аны салуда Шөгер нефтебитум заводы зур ярдәм күрсәтә.

1933-1934 нче елларда яңа мәктәп бинасы салына. 1935 нче елда урта мәктәп ачыла.

1937-1938 нче уку елларында районда беренче чыгарылыш була. Мәктәп директоры булып *Хәлимов* эшли. Сугыш башланганчы бу мәктәптә *Фәтхуллин Фатыйх, Каюмов Хәмәт, Туктаров, Дәрҗеманов Зыя, Хәеров Гариф* һәм башкалар укыта.

Мәктәп районда үзенең зыялы укытучылары һәм укучылары белән дан тота, ләкин репрессия җилләре аны да әйләнеп үтми.

***“Сугыштан соңгы мәктәп.”***

1945 нче ел: Иске Шөгер мәктәбе үрнәк мәктәпләрдән санала, коллективы зур, бердәм була.Мәктәп директоры *Фасеев Салих Фатыхович* була.Укытучыларга бу чорда көненә 300 грамм он, өч көнгә бер арыш ипие бирәләр.

Химиядән- *Закиров Габделхак,* физку-льтурадан- *Дәүләт Миңнебаевич,* геогра-фиядән- *Ибраһимова Мәрьям Шәриповна,* рус теленнән- *Гарифуллина Сорур Валеевна,* физикадан- *Сәлимов Мөхтәр Шәрипович,* сызымнан- *Һилалов Җәүдәт Гатич,* башлангыч сыйныфларда-*Галимова Мәсгүдә Сәлимҗанов-на, Гильметдинова Асия Гильметдиновна, Таһирова Миңнур, Әһлиуллина Миңнур,* завуч-*Закирова Суфия Закировна. Салимовларны* киләсе уку елында завод мәктәбенә күчерәләр.

Укытучы агитатор да була.Кич белән педсовет, агитколлектив, идарә утырышы,авыл советы утырышы - боларның берсеннән дә калырга ярамый. 1947 нче елның җәендә мәктәпнең түбәсеннән яңгыр үтә башлагач, такта ярып такта белән ябалар.Бу ел бик кыйммәтчел ел була.Бодай оны 700сум, бу укытучының айлык хезмәт хакы.Шушы ук елны Иске Шөгер мәктәбенә химия-биология укытырга *Җәмилов Р.Ш* килә.Ул Казан кызы *Кәримова А. В.га* өйләнә һәм мәктәптә беренче тапкыр инглиз теле укытыла башлый.

## *“Нефть эзләү эшләре.”*

Элек заманнарда ук безнең якның олы кешеләре Шушма елгасы суы өстендә майлы таплар күрүләрен сөйлиләр.Моның турында *П.С.Паллас,И.И.Лепехин,П.И.Рычков,И.П.Фальк* кебек галимнәр эшләрендә язылган.

18-19нчы гасырларда нефть эше белән галимнәр, геологлар *И.Лангел, И.В.Широкшин, А.Р.Герегрос* һәм башкалар шөгелләнә.

Лениногорск районында скважина белән бораулау методын беренче тапкыр Бөгелмә алпавыты, отставкадагы капитан *Я.Н.Малаки-енко* сыный.Бу эшне киң җәелдерә Америка эшмәкәре *Шандор,* ләкин ул уңышка ирешә алмый.

19 нчы гасыр ахырында девон катлавының нефтьле булуы турында фикер әйтелә. *И.М.Губкин* бу идеяне үстерә һәм төз фәнни нигез булдыра.Аның идеяләре нигезендә 1939 нчы елда “Татгеологоразведка” тресты төзелә.

Эзләнү эшләре авыр сугыш елларында да дәвам итә.Буровойда күбесенчә хатын-кызлар эшли:*Мөхтәрәмә Харрасова, Мәрвия Шәйхет-динова, Фатыйма Хәсәншина, Гаян Фаязова* һәм башкалар.

Нефтьчеләрнең хезмәт батырлыгы эзсез үтми. 300 еллык хезмәт нәтиҗәсе буларак 1943 нче елның 3нче августында Яңа Шөгер авылы янында нефть таба.

*Вакыйгалар хроникасы.*

XVIIIгасыр-

П.С.Паллас,И.И.Лепехин,П.И.Рычков,И.П.Фальк безнең төбәктә фәнни тикшерү эшләре алып баралар.

1637нче ел-

пушкар приказы язмаларында Шөгер деге͏т чокырлары телгә алына.

1717нче ел-

Готлиб Шобер безнең төбәкнең нефть чыганакларын тасвирлый.

1838нче ел-

Шөгер авылында беренче нефтьчеләр пәйдә була.

1865нче ел-

П.В.Еремеев Шөгер авылында була һәм тикшерү эшләре белән шөгелләнә.

1874-1877нче еллар-

Америка эшмәкәре Шандор скважина белән бораулау эшләре алып бара.

1940нчы ел-

беренче номерлы скважина төзү башлана.

1941нче ел-

скважинада бораулау эшләре башлана.

1943нче ел, 3нче август-

беренче номерлы скважина нефть бирә башлый.”

***“Шөгер нефтепромыселы”.***

1943 нче елның 3 нче августында беренче номерлы Шөгер скважинасы 617,5 метр тирәнлектән нефть алына башлый. Бу шатлыклы вакыйга Гариф Хамидуллович Хамидуллин сменасына туры килә.

Ачыш шатлыгын шулай ук Шөгер нефтеразведка начальнигы А.В.Лукин, өлкән инженер И.Г.Шеламонов, өлкән геолог С.П. Его-ров уртаклаша.

1944нче елның 28 нче маенда мастер Я.М.Буянцев җитәкчелегендәге бригада икенче скважинада нефть чыгара башлый.

1945нче елның сентябрендә нефтепромысел хуҗалыгын оештыру башлана.Авырлыклар инженер-техник кадрлар һәм квалификацияле эшче - нефтьчеләр җитмәү белән аңлатыла. Ел ахырына монда директор итеп *А.И. Се-менов* билгеләнә.

1946нчы елда Шөгер нефтепромыселы нефтьне промысел һәм җирле предприятиеләр өчен генә җитештерә. Шөгердән Келәүлегә нефтьүткәргеч төзелә, шуның өчен эшче көчләр Татарстанның унбер районыннан җыела. Шөгер нефте Татарстан нефтенең зур киләчәгенең башы була. Нефтьчеләр шәһәрләре буларак Лениногорск, Әлмәт, Азнакай шәһәрләре үсә.

## ***Шөгер нефтебитум заводы тарихы.***

19 нчы гасыр ахырында Шөгер нефтебитум заводына нигез салына. Аңа нигез салучы дип Америка эшмәкәре Шандор санала. Ул разведкалар ясый һәм монда нефть барлыгын белә. Бу вакытта җир җәмгыять милкендә була. Шандор завод төзергә рөхсәт ала һәм ташның иң калын җиреннән ачтыра башлый. Ташны алгач аңа проба ясап кайната башлыйлар. Шандор Шөгер нефтенә төшеп җитә алмый, ләкин нефтебитум заводына нигез сала. Заводның беренче директоры *Павел Андреевич Малинычев.*

1914 нче елда беренче бөтендөнья сугышы башлангач завод ябыла. 1917 нче елда ул яңадан эшли башлый. 1921 нче елгы ачлык та заводны әйләнеп үтми, эшчеләр ачлыктан интегә.Павел Андреевич Мәскәүгә китә һәм 1922 нче елда аннан бер вагон бәрәңге килә.1923 нче елда завод тагын туктый. 1927 нче елның апрелендә яңадан эшли башлый.Директор итеп *Ткачев* билгеләнә.Завод зурая, пар машиналары куела, 200-300 кеше эшли башлый.Завод җәй көнендә су буенда ачык һавада эшли, ә кыш көне тышта эшләү туктала, шахта эчендә эшли башлыйлар. 1934 нче елда яңа директор *Басов* килә. Ул килгәч завод тагын да зурая. Казаннар механикалаш-тырыла.Шахталар электрлаштырыла, ташны рельс буйлап ат белән чыгара башлыйлар. Ул вакытта бер елга 1000 тонна чыгарырга йөкләмә алалар.

## ***“Беренчеләр.”***

1938нче елда беренче нефтьчеләр Иске Шөгер авылына килә.Җитәкчеләре : директор *Алексеев,* мастерлар *Козихин, Двисилов* һәм башка читтән килгән тәҗрибәле белгечләр.

Төбәктән беренчеләр булып эшкә *Рәүф Мәүлетов, Мәгнәви Хәнәфиев, Гарифулла Вәлиев, Фәсхетдин Шәрәфетдинов* һәм башкалар килә.

Эшчеләр агач әзерли, җир казый. Хезмәт шартлары бик авыр, бөтен эш кулдан башкарыла. Эчәргә су да җитми. Ике хатын-кыз кул насослары белән Шушмадан су суырта. Аеруча төнге сменада авыр була бөтен җирдә факеллар төтенли.

Шөгердә буровой төзү һәм җыю исkиткеч авыр була, чөнки ул тимер һәм су юлларыннан бик еракта, яз-көз айларында юллар бөтенләй ябыла.Шуның өчен беренче скважинаны бораулау урынына 1940нчы елны төзи генә башлыйлар.

Сугышның беренче көннәрендә үк иң тәҗрибәле белгечләр сугышка китә. Автомобилләр, тракторлар да сугышка алына.

1941 нче елның июлендә бораулау эшләре башлана.Бу эшләргә *Гариф Хәмидуллович Хәмидуллин* җитәкчелек итә. Аның бригадасы ялдан да баш тарта, эшләгән акчаларын оборона фондына бирә. Безнең якташларыбыз *Шәрифуллин Зиннәт , Шәрәфетдинов Фәсхетдин* Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек була.

***Әминә Каюмовна Каюмова.***

Иске Шөгер мәктәбендә укыткан беренче югары белемле укытучы ,Татарстанның ат-казанган укытучысы исемнә бернче лаек булучы Каюмова Әминә апа була.

Әминә Каюмовна 1909 нчы елның 17 нче июнендә Әлмәттә туган.Башта авылның укымышлы кешеләреннән гарәп хәрефләре белән укырга-язарга өйрәнгән, аннары җиде-еллык мәктәптә белем алган.1920 нче елда ул Бөгелмәдәге икенче баскыч татар мәктәбенә укырга керә.Фазыл Туйкин, Һади Атласиларда белем ала.

Бөгелмә педтехникумын уңышлы тәмам-лагач, ул Шөгер урта мәктәбендә эшли, читтән торып Казан педагогия институтына укырга керә. Ләкин сугыш башлана. Әминә апа институтның өченче курсын гына тәмам-ларга өлгерә

1942 нче елда аны Шөгер районындагы иң зур авылларның берсенә- Түбән Чыршылыга директор итеп билгелиләр.Ире-Таһиров Ризак яу кырыннан кире кайтмый.

Институтны тәмамлый, 40 елга якын педагогик эштә эшли, өч бала үстерә, шуның икесе академиклар,”Почет билгесе” ордены, медальләр, Мактау грамоталары белән бүләкләнә. 23 ел Шөгердә яши һәм эшли. Озак еллар буе тырыш хезмәте өчен “*Татарстанның атказанган укытучысы*” дигән мактаулы исемгә лаек була.

***Нурлыгәрәев Җәмил Сабирович.***

Нурлыгәрәев Җәмил Сабирович 1929 нчы елның 1нче январендә ТАССР Лениногорск районы Иске Шөгер авылының балта остасы гаиләсендә туа.

1937-1947 нче елларда Иске Шөгер мәк-тәбендә белем ала.

1947-1950нче елларда Иске Шөгер һәм Сугышлы җидееллык мәктәпләрендә башлан-гыч класс укытучысы булып эшли.

1950нче елда Югары Чыршылы башлангыч мәктәбе җитәкчесе итеп билгеләнә.

1951 нче елны Түбән Чыршылы җидееллык мәктәбенә география укытучысы итеп билге-ләнә, 1957 нче елдан шушы ук мәктәпнең завучы була.

1963 нче елдан Иске Шөгер урта мәктәбендә эшли, 1972 нче елдан директорның укыту эш-ләре буенча урынбасары.

1949нчы елда читтән торып Бөгелмә педа-гогик училищесын , ә 1955 нче елда Казан Дәү-ләт педагогик институтының географик факуль-тетын тәмамлый.

1984 нче елда *“РСФСРның атказанган укытучысы”* дигән исем бирелә.

## *Колхоз тарихы.*

1918 нче елның февралендә Шөгердә дә Совет власте урнаша, беренче авыл Советы барлыкка килә, аның рәисе итеп Ризван Мөхәммәтҗанов сайлана.

1931 нче ел ахырына Иске Шөгернең барлык халкы диярлек “Үзәк” колхозына керә. Беренче рәис- *Хәмзин Гобәй*. Күмәк хуҗалык белән икенче елдан *Ризак Таһиров* идарә итә.Басулары чокыр-чакырдан торган колхоз бик мантымый: иген уңышы түбән, терлекләр аз.1935 нче елда колхозга беренче машина кайта, аны *Ярулла Насретдиновка* ышанып тапшыралар.Беренче тракторчы *Барый Рәхимов* була.Икенче трактор 1932 нче елда кайта.Колхозның эше рәтләнеп килгәндә генә Бөек Ватан сугышы башлана.Бөтен эш яңадан ат көче белән башкарыла башлый. 1944 нче елда колхоз икегә бүленә: “ Уңыш” һәм “Үзәк”.

1950 нче елда “Үзәк”, “Уңыш”, “Партизан”, һәм “Сортовод” колхозлары бер хуҗалыкка берләшеп, “Уңыш” колхозы хасил итәләр (1960 нчы елдан “Шушма”). Эреләндерелгән хуҗалыкның рәисе *Зыя Мөхәммәт улы Әхмәтов* була. Миллионер колхозның *19 алдынгысы* хөкүмәтебезнең орден-медальләре белән бүләкләнде.

Сугышның беренче көннәре.

1941 нче елның 22 нче июнендә башланган Бөек Ватан сугышы Иске Шөгер авылы халкының да тыныч тормышын өзә. Канлы сугышның иң беренче көннәреннән үк *400* дән артыграк ир-егет һәм хатын-кызлар фронтка китә, аларның *210* сы кире әйләнеп кайтмый.

Әхмәтҗанов – Иске Шөгер авылы нефтчесе.

Лукин Анатолий Венедиктович- Шөгер нефтеразведкасы җитәкчесе.

Сямриков Герасим Петрович нефтепромыселда катлаулы эшләр буенча өлкән мастер.

Шөгер нефтеразведкасынада эшче- Галеева М.Ш.

Шөгер нефтеразведкасында буровой эшчесе- Мөхәммәтхаррасова М.М.

Татарстан нефтен мастер Хәмидуллин Г.Х. ача.

Советлар Союзы Герое С.Садриев һәм авың хатыны нефт-чыгаруда эшлиләр.

Шөгер эреләндерелгән нефтепромыселы(1946 ел).

РФның Атказанган укытучысы Нурлыгәрәев Җ.С.

РФның Атказанган укытучысы Зиангирова М.З.

Мәктәп директоры-Валеев Н.Н.

Мәктәп директоры-Валеев М.В.

Мәктәп директоры-Сөләйманова В.З.

Яңа мәктәп ачу тантанасы.

Беренче алты яш-лекләр.(1968-1969).

Иске мәктәптә зарядка.

Иске мәктәптә “Соңгы кыңгырау”.

Күңелләрдә гомерлеккә калсын кыңгыраулы мәктәп еллары...

Мәктәп бакчасында Зиангирова М.З. укучылар белән(1948ел).

1953ел. Дәрес бара...

Өйрәтәләр мәктәпләрдә...

Өлкән сыйныф укучылары директор Фасеев белән(1962).

Яңа мәктәпкә нигез салу.

Пионерлар укуда да сынатмый.

“Кара” белән язган чаклар.

Укучылар 1930 нчы елда.

Юбилей.

“Тантаналы вәг-дә”.
“Аҗаган” патриотик уены.

Пионер байрагы кертү.

Колхозчылар(1933 ел).

Ял вакытынад агитатор чыгышы.(1961).

30нчы елларда клуб активы.

Тары җилгәрү.

Җәйге кыр эшләренә әзерлек смотры(1934 ел).

Кашаповна Зәйнәп Кашаповнага Татарстанның атказанган укытучысы исеме бирелде. Гомере буена үзенең йөрәк җылысын балаларга биргән, гадел, йомшак табигатьле Зәйнәп Кашаповнага мәктәп өчен бик кадерле.

Халимова Лира Александровна күп еллар рус телен һәм әдәбиятын укытты. “Аеруча хезмәт күрсәткән өчен һәм “Халык мәгарифе отличнигы” значогы бирелде.

Ахмерова Венера Закуановна укыту һәм тәрбия эшендә күрсәткән уңышлар өчен ул “Өлкән укытучы” исеменә лаек булды.

Мәктәп белән 18 ел җитәкчелек иткән Валеев Миргасим Валеевич Хезмәт кызыл байрагы ордины, РСФСР һәм СССР халык мәгарифе Отличнигы значогы белән бүләкләнде. Лаеклы ялда булуына карамастан, мәктәп коллективының якын дусты һәм киңәшчесе.

***Хайруллина Мөхтәрәмә.***

Мөхтәрәмә апа 1922 елның 10 февралендә Шөгер районының Иске Шөгер авылында туа. Әнисе – Миңнеәсма Хөснетдин кызы һәм әтисе – Гарифулла Хайрулла улы бик авыр тормыш алып барган. Аларның гаиләсендә 8 бала булган һәм 5 енчесе булып Мөхтәрәмә апа туган. Алар барлыгы ике малай һәм алты кыз булганнар. Мөхтәрәмә апа бик авыр шартларда үскән. Кычыткан, балтырган, зәрдә ашлары ашап үскәннәр. Ул үзе дә:

- Күрше остабикә әбидән бер кашык тоз сорап керә торган идек, - ди.

Балаларын ач калдырмас өчен, әниләре үзләренең хуҗалыкларында күп итеп бәрәңге, тары, пәҗә һәм башка үсемлекләр үстергән, ситса суктырып киемнәрне дә үзе тегеә торган булган.

1933 елны 17 яшендә Мөхтәрәмә апаның олы апасы Мөнәвәрә дробилкада тапалып үлгән. 1934енче елны 47 яшендә әтисе үпкә чиреннән үлә. әтисе үлгәч тә,Мәхтхрәмә апаның абыйсы Инсафетдин зводтагы хоз. частька эшкә урнаша. Ләкин 1940 нчы елда йөрәк өянәге белән ул да үлеп китә. Шуннан соң бөтен тормыш авырлыклары Миңнеәсма апа җилкәсенә төшә.

Мәхтәрәмә апа сигез классны укып бетергәч, завод конторына счетовод булып эшкә урнаша. Аннан соң аны завод шахтосына күчерәләр. Ләкин анда бер ел да эшләми, гудроннар бетү сәбәпле, шахтаны япканнар. Шахта ябылгач, завод дирек-торы Мөхтәрәмә апаны Шөгер районы Райпосына бухгалтер ясап эшкә алган.

1941 елда, сугыш башлангач, Мөхтәрәмә апаны Шөгер районы авыл советына счетовод итеп алалар. Анда ул берюллы счетовод та, секретарь да, начальник ВОЗ да булып эшли. Шул елларда аның аша 1енче партиядә - егетләрне, 2 енче партиядә кызларны сугышка алып киткәннәр, ә 3 енче партиядә Мөхтәрәмә апа эләккән. Шулай итеп, Мөхтәрәмә апа сугышка 1943 елның 22енче июнендә киткән.

Сугышның беренче көннәрендә аларны поезд белән Казанга илткәннәр. Казанга кич белән генә барып төшкәннәр. Ул кызлар арасында Хөснетдинова Мәкбүлә, Вилданова Хәлимә, Дау-това Наилә, Билалова Рәсимә, Шакирова Зәйнәп, Бадыкшанова Зәйнәп һ.б. барлыгы – 22 кыз, үзләре теләп, фронтка китәләр. Икенче көнне Мөхтәрәмә апаны һәм башка солдатларны пушкадан атарга өйрәтәләр. Бу хәзерлек курслары 3 ай дәвам итә.

Шуннан соң Мөхтәрәмә апаларның сугышчан юллары Белоруссиянең Сарын шәһәрендә 1873 енче зенитно-артилерейский полкның 4енче һәм 5 енче дивизионнарында башлана. Аннары соң аларны Гомель, Ковель, Брест шәһәрләренә күчерәләр. Бөтен шәһәрләрдә дә Мөхтәрәмә апа зенитчы булган. Озак барган шушы сугыш елларында, төннәр буе алар күккә карап, дошманның самолетларын бомбага тота торган булганнар. Ә көндезләрен исә снарядлар чистарт-каннар, яраланган солдатларны дәвалаганнар. Шулай итеп, көне-төне йокламыйча, алар безнең киләчәгебез әчен дошманга каршы сугышканнар. Мөхтәрәмә апа

әйтүенчә, кораллар җткән, снарядларны да китереп торганнар, ә ашау ягы мәсьәләсене бик авыр булса да, ашарга да булган, ачка үлмәгәннәр. Көнгә 400 грамм ипи, шулпа, бәрәңге, умач кебек әйберләр белән тукланганнар. Бер пушкада алар җиде кеше булганнар – 1- командир, 1се әйләндерә торган, 2 кеше наводчиклар, 1 кеше заряжатель, 2 кеше – патрон бирүчеләр.

Дошман самолетларын аткан вакытта, Мөхтәрәмә апаның бармагына снаряд кыйпылчыгы тиеп, беразын кисә. Ләкин ул аны, самолетлар китеп беткәс, сугыш кыры бераз тынычлангач кына күрә. әле аны да командир взвода әйтә. Шундый хатирәләр Мөхтәрәмә апаның күңеленнән беркайчан да китми.

Юнусова Җәүһәрия апа истәлекләреннән.

Җәүһәрия апа эшче-крестьян гаиләсендә туа. 1932 елда укырга керә, ләкин мәктәпне тәмамлый алмый, сугыш башлана. 1943нче елның апрелендә үзе теләп сугышка китә. Яраланып госпитальдә ятып чыга. Аның истәлекләре: “ Без өч татар кызы
Казанга хәтле килдек. Казанда безне аердылар. Мин 3нче Украина фронтына эләктем. Татар кызларыннан берүзем идем.

Барып урнашкан төнне ук миңа сакка чыгарга туры килде. Мин бер җимерек таш йорт өстенә менеп утырдым да, шуннан һаваны күзәттем. Караңгы төн иде. Ләкин курыкмадым. Уйларга батып, киләчәк якты тормыш турында уйлап торганда бер бомбардировщик килеп чыкты. Мин тревога бирдем. Мине каушап калмавым, вакытында хәбәр бирүем өчен “ Батырлык өчен “ медале белән бүләкләделәр.

Бервакыт, сугыш тынган арада, ял вакытында, чия ашап йөри идек. Кинәт алда ике кеше күренде. Икесенең дә кулында ак пакетлар иде. Болар кое янына килделәр дә, су эчтеләр. Без штабка хәбәр бирдек. Аларны тоттылар, ләкин инде коены агулап өлгергәннәр иде. Анда да безгә рәхмәт белдерделәр,”- дип сөйләде Җәүһәрия апа

# Социалистик Хезмәт Герое
# Зиннәт Шарифуллин.

Иске Шөгер мәктәбендә укыганда ук тыйнак, игътибарлы һәм тырыш булуы белән аерылып тора.

Бөек Ватан сугышында бронетанк командиры, лейтенант була.
Зиннәт Шарифуллин 1950нче елның апреленнән Шөгердәге беренче скважиналарда дизелист булып эшли башлый. 1952нче елдан –оператор.

Аның җитәкчелегендә операторлар скважиналарны электролаштыралар, җиһазлыйлар. Барлык 35 скважина өзлексез контрольда торсын өчен яңа эш алымнары кертә.

Зиннәт Шарифуллин үзе дә һәр елны 4-5 радионализация тәкъдимнәре кертә. Аның тормыш кагыйдәсе:” Нефтьче скважиналар өчен кирәк булган бөтен һөнәрне белергә тиеш”. Ул тракторчылык, электрик, машинистлык, слесарь-ремонтчылык һөнәрләрен үзләштерә.

Үзенең бай тәҗрибәсен яшьләргә бик теләп өйрәтә.

Ул-актив җәмәгать эшчесе.

Хәзерге вакытта ул лаеклы ялда. Әлмәт шәһәрендә яши.

Социалистик Хезмәт Герое
Миңнекәев Мәсгут .

Мәсгут Миңнекәев 1930 нчы елның 11 нче апрелендә Шөгер районы Яңа Елховой авылында туа.

1950 нче елда Иске Шөгер урта мәктәбен тәмамлый.

1956 нчы елда Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайтка.

Миңнебай Газ эшкәртү заводында егерме ел оператор булып эшли башлый.

Читтән торып Лениногорск нефть техникумын тәмамлый. Гади эшчедән инженер дәрәҗәсенә кадәр үсә.

Хезмәттә күрсәткән батырлыклары өчен медальләр һәм күп төрле грамоталар белән бүләкләнә.

1966 нчы елны мактаулы исемгә- Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек була.

Хәзерге вакытта ул лаеклы ялда булуына карамастан, җәмгыять эшендә актив катнаша.

Бүгенге көндә Әлмәт шәһәрендә яши.

Социалистик Хезмәт Герое
Шәрәфетдинов Фәсхетдин .

Шәрәфетдинов Фәсхетдин Шөгер мәктәбен 1941 нче елда тәмамлый.

Шөгердә нефтеразведкада эшли башлый, ләкин озак эшләргә туры килми.

Ул үзе теләп Бөек Ватан сугышына китә һәм 1946 нчы елда гына демобилизацияләнеп туган якларына кайта.

Фронтта күрсәткән батырлыклары өчен “Кызыл йолдыз” ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң, элеккеге эше – нефтеразведкада эшли башлый. Башта эшче, аннары верховой, бурильщик, инструктор була. 1949 нчы елдан ул буровой мастер булып эшли.

Аның бригадасы 140 лап тирән разведка сква-инасы бораулады.

Бу бригада 1963 нче елдан бирле “Коммунистик хезмәт бригадасы” исемен йөртә.

Лаеклы ялга чыккач та ул җәмәгать эшләрендә актив катнаша.

## *Җәмит Рәхимов.*

Җәмит Рәхимов үзенең әсәрләрендә туган як табигате матурлыгына аеруча зур урын бирә. Туган ягын, Шөгерен, “илкәемнең назлы бер төбәге” дип җырда мактаган язучы, аның матурлыгына сокланып кына калмый, аны сакларга, якларга өнди. Җәмит абый туган якны чиксез зур, тирән мәхәббәт белән ярата.

Туган җир! Нинди генә булма, һәркем өчен бер генә бит син. Кешенең күңел түрендә мәңге онытылмас ләззәтле сагыш булып гел генә яшисең. Йә кылганлы, әремле дала булып, йә мәгъруур, мәһабәт таулар булып. Берәүләр өчен түбәләрен ак чалма – болыт ураган тау итәкләрендә ерак – еракларга сузылган аллы – гөлле ләлә кыры син; икенчеләргә - язларын ак күбеккә батып утырган бакча - әрәмә; өченчеләргә - инеш буенда эссегә әлсерәп утырган өянкеләр. Кайберәүләр сине офыктан – офыкка җәйрәп яткан бодай кыры итеп күрә, кайсылары тау күкрәген ярып чыккан терекөмештәй саф сулы чишмә дип белә. Кемгә бәбкә үләне каплаган авыл урамы, кемгә ак таш пулатлары тезелеп ктткән ыгы – зыгылы кала син. Нинди генә булма, һәркайсыбызга газиз син, кадерле син!

Садриев Самат Салахович.

Советлар Союзы Герое Садриев С.С. 1920 елның 15 январендә Лениногорск районы Иске Шөгер авылында туа.

7 сыйныфны бетергәннән соң Ярославль туку фабрикасында слесарь булып эшли.

1941 елның 22 июнен Садриев Грузиянең Кутаиси шәхәрендә каршылый.

Армиягә аны туган авылыннан 1942 елда алалар. Казанда танкистлар мәктәбен тәмамлап сержант дәрәҗәсен ала. 1942 елның ахырында Сталининградка 101 нче аерым танк бригадасына җибәрелә. Монда Америка танклары "Шерман"нар кулланыла. Курск янында да сугышы, 5 ай госпитальда ята.

Терелеп чыккач аны 47 армияга җибәрәләр. Садриевны 667 укчы пол кның автоматчылар отделениясенә командир итеп билгелиләр. 47 армия генерал Конев җитәкчелегенддәге фронт составына керә. Алар Украинаны азат итәләр, Днепрга килеп җитәләр.Хәрби бурыч : килгәч тә үк Днепр аша үтәргә һәм Киев шәхәрен алырга.

1943 елның 24 сентябрендә Днепрны кичеп чыгу башлана. Саматов җитәкчелегендәге отделение иң беренчеләрдән булып елганы кичә.

Садриевның батырлыклары:беренче батырлык – ул уңышлы елганы кичү. Ул үзеннән үзе генә килми – елганы кичкәнче сержант солдатларны өйрәтә.

Икенче батырлык – уң як ярда уңышлы һөҗүм оештыру. Бу да акыл һәм хәйлә белән уйлап эшләнә.Сержант шәхсән үзе бу көрәштә 7 гитлерчыны юк итә.

Өченче батырлык –яулап алган җирне саклау.Безнең сугышчылар Днепр аша чыккан арада алар фашистларның пулемет расчетын арттан килеп юк итә.

Дүртенче батырлык-бу 1943 елның 25 сентябрендәге каты сугыш.Ул тагын 2көн дәвам

итә.Дошманның һөҗүмнәре туктаусыз дәвам итә, ләкин сугышчылар бирешмиләр.Бөтен 47нче фронт Днепр аша чыкканчы сугышны дәвам итәләр.

1943 елның 3 ноябрендә Киев өчен сугыш башлана,6 ноябрьда ул алына.

Житомир яны иде бер айлык камалыштан чыкканнан соң Садриевны Головачев җитәкчелегендәге 23 мотострелковый бригадага куялар.Шушы гаскәрләр белән ул Берлинга кадәр барып җитә.

Сандомир янында Самат Садриев командуюэий янына чакырыла .

Аны Советлар Союзы Герое Грамотасы,Ленин ордены һәм Алтын йолдыз медале белән бүләклиләр.

Советлар Союзы Герое Мурзин Ибраһим Хөсәен улы.
Мурзин Ибраһим Хөсәен улы 1916 елда Иске Шөгер авылын-
да туып үсә,1935 елда Иске Шөгер урта мәктәбеннең 7 клас-
сын тәмамлап,1935-1936 елларда Шөгер нефтебитум заво-дында кочегар булып эшли.
 Гвардия өлкән серңант Мурзин И.Х.үзенең сугышчан юлын
Сталинград астындагы сугышлардан башлый.Ул үзенең рас-
четы белән күп фронтларда була.1944 елның июленнән баш-
лап 1-Украина фронты составындагы 158-гвардия артиллерия полкында орудие командиры булып авыр сугыштан юл үтә,Одер елгасына барып җитәләр.

Совет Армиясе

Ушполис Григорий Саул- улы.

Ушполис Григорий Саул- улы 1923 елның 26 декабрендә Литва Республикасының Игналин районы Яңа Даугелишкәй авылында туган. Милләте буенча яһүд. 7 сыйныф бетергән. Хәрби хезмәткә алынганчы комбайнчы була. 1942 елның февраленнән Совет Армиясе сафында, хәрби хезмәткә ТАССРның Яңа Писмән райвоенкоматы тарафыннан чакырыла. Бөек Ватан сугышында шул елның декабреннән катнаша. 1944 елдан КПСС әг-засы.

1нче Балтыйк буе фронтының 2нче гвардия армиясе 16нчы укчы дивизиясендәге 249нчы укчы полкта орудие командиры ефрейтор Ушполис 1944 елның 12 октябрендә Неман елгасы буендагы Пачечяй торак пункты янәшәсендәге пози-ияләрне дошман һөҗүменнән саклауда аеруча батыр сугыша. Алгы сызыкка чыгарып куелган тубыннан атып, дошманның һөҗүм итүче 2 танкын сафтан чыгара. Тубы атмас хәлгз килеп җимерелгәч, яраланган булуына карамастан, кулына авыр граната алып, тагын бер танкны шартлатып юк итә. Шушы батырлыгы өчен 1945 елның 24 март Указы белән Ушполиска Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

1945 елда сәясәт бүлеге офи-ерлары курсын тәмамлый. Ушполис 1947 елда майор дәрәҗәсендә отставкага чыга. 1949 елда Литва КП ҮК каршындагы партия мәктәбен тәмамлый. Ул Ленин, 1 дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медал-ләре белән бүләкләнгән.

Хәлиуллин Мисбах Хәлиулла улы.

Хәлиуллин Мисбах Хәлиулла улы 1916 елның 12 мартында хәзерге Татарстан Республикасы Лениногорск районының Сугышлы авылында туган.Милләте- татар. Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумын, аэроклуб тәмамлаган. Колхозда, районның җир бүлегендә эшләгән, булачак очучыларны һөнәргә өйрәткән. 1936 елдан Совет Армиясендә. 1940 елда Энгел- шәһәрендә очучылар мәктәбен, 1941 елда Хәрби һава көчләренең Югары штурман мәктәбен тәмамлаган.

1943 ел маеннан Бөек Ватан сугышында.

783нче штурмлау авиа-иясе полкында, 4нче штурм авиа-иясе корпусы, 4нче һава армиясе, 2нче Белоруссия фронты эскадрил-я командиры Хәлиуллин 1945 елның апрел- аена кадәр дошман ныгытмаларын һәм гаскәрләрен штурмлау өчен 88 сугышчан очыш ясаган, 16 һава сугышында дошманның 3 самолетын бәреп төшергән. Советлар Союзы Герое исем 1945 елның 16 августында бирелгән.

1946 елдан КПСС әг-засы. Югары офи-ерлар курсларын тәмамлаган, полковник дәрәҗәсендә отставкага чыккан.

Ленин, өч Кызыл Байрак, Александр Невский, 1 дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медал-ләр белән бүләкләнгән.

1983 елның 18 апрелендә вафат. Казанның Арча зиратынад җирләнгән.

Заварыкин Иван Александр улы.

Заварыкин Иван Александр улы 1916 елның 23 октябрендә хәзерге Татарстан Республикасының Лениногрск районының Иске Куак авылында крест-ян гаиләсендә туган. Милләте-рус. Урта белемле. 1936 елдан Совет Армиясендә. 1938 елда Энгел- хәрби авиа-ия учили-есын тәмамлаган.

Бөек Ватан сугышы башлануга- фронтта. 1943 елдан КПСС әг-засы.

4нче Украина фронты сооставындагы 8нче һав армиясенең 7нче штурм авиа-иясе корпусына караган 206нчы штурм авиа-иясе дивизиясенең 806нчы штурм авиа-иясе полкы командирының һав-укчы хезмәте буенча ярдәмчесе капитан Заварыкин 1943 елның ноябренә кадәр 104 сугышчан очыш ясап, дошманның 40 танкын, 130 автомашинасын яндырагн, 20 артиллерия батареясын сафтан чыгарган, аэродромнардагы 7 самолетнв һәм башка хәрби техниканы юк иткән. Советлар Союзы Герое исеме 1944 елның 143 апрелендә бирелгән. Ленин ордены һәм ике Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән.

1945 елныэ 21 февралендә сугышчан бурычын үтәгәндә һәлак булаган.

Литвадагы Ма-ейкяй шәһәрендә, хәрбиләр зиратында җирләнгән.

Иске Куак авылында аның истәлегенә обелиск куелган.

Яницкий Василий Иван улы.

Яницкий Василий Иван улы 1916 елның 26 февралендә хәзерге Татарстан Республикасы-ның Лениногорск районы Иске Куак авылындагы крест-ян гаиләсендә туа. Милләте-рус. 7 сыйныф белемле. Колхозда эшли. Казандагы механика техникумының 2 курсын тәмамлый. 1939 елда Тамбов очу учили-есын тәмамлый. Көнбатыш Себер идарәсендә очучы булып эшли.

1940 елдан Совет армиясе сафларында. Очуылар хәзерләү Югары курсларын тәмамлый, Киев хәрби округының 227нче укчы авиа-ия полкы хәрби очучысы була.

1941 елның июненнән Бөек Ватан сугышын фронтларында. 52нче бомбага тоту авиаполкының эскадрил-я командиры урынбасары өлкән лейти=енант Яни-кий дошманның күп кенә аэродромнарын һәм гаскәрләрен юк итүдә катнаша.

1942 елның 20 июнендә Яни-кий каты яралана, шуңа да карамастан үзенең самолетын аэродромга утырта. 1942 елның 12 августында өлкән лейтенанат Яни-кийга күрсәткән батырлыгы, җиңүгә омтылганы, хәрби бурычка тугры калганы өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелә. 1943 елдан КПСС әгъзасы.

1946 елда һава академиясен тәмамлый. 1970 елда отставкага чыга. Ленин, Кызыл Байрак, 1 дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медал-ләр белән бүләкләнә. 1993 елда вафат.

# Баһаветдинов Гыйл-ми Абзал улы.

Баһаветдинов Гыйл-ми Абзал улы 1924 елның февралендә хәзерге Татарстан Республикасы Лентногорск районының Сарабиккол авылында туган. Милләте- татар. Тулы булмаган урта мәктәпне тәмамлый,колхозда эшләгән.Кызыл Армиягә 1942 елда КПСС әг-засы

1259нчы укчы полкның ( 381нче укчы дивизия, 21нче армия,Ленинград фронты ) пулемет расчеты командиры сер-ант Баһаветдинов 1944 елның 10 июнендә Карел бугазы оборонасын өзгән вакыттагы сугышларда дошманның ныгытмада үз артыннан иярткән. Дзотка гранаталар ыргытып, взводның алга баруын тәэмин иткән.Сафтан чыккан командирны алыштырып, сугышчыларны күп тапкырлар һөҗүмгә күтәргән.Ике тапкыр яраланса да, сугыш кырыннан китмәгән.

***Әсхәт Кәбиров.***

Әсхәт Кәбиров 1924 елны Шөгер авылында туа. Безнең мәктәпнең алдынгы укучыларының берсе була. Шөгер урта мәктәбен тәмамлаган көнне егетләр һәм кызлар Зубай чишмәсе буена бик матур әрәмәлеккә бәйрәм итәргә җыелалар.Әсхәт гармунда сыздырып җибәрә, яшьләр кушылып җырлыйлар, бииләр. Шулай гөрләшеп уйнап ятканда, Шөгер ягыннан атка атланган бер кеше : ”Сугыш башланган”- дигән хәбәр китерә. Тынлыкны бозып, Әсхәт сүз башлый:”Дуслар, мин беренчеләрдән булып фронтка китәм”. Ул көнне яшьләр күмәкләшеп туган илне сакларга ант итәләр. Әсхәткә әнисе дә, абыйсы да:”Әле син бик яшь, әллә берәр ел сабыр итәсеңме”- дип әйтеп карыйлар. Ләкин ул сүзендә нык тора. “Илебез язмышы хәл ителгәндә, фашист ерткычлары илебезгә басып кергәндә, мин шушы буем, шушы сыным белән өйдә ята алмыйм”- ди ул. Киткән вакытта ул:”Әни, Сәрия апа кайгырмагыз, мин чыныгып, нык кеше булып кайтырмын, без барыбер җиңәрбез. Комсомолец Әсхәт, яше җитмәүгә карамастан, үзе теләп фронтка китә. Башта Чиләбе танк училищесында укый. 1942 елның 26 сентябрендә Сталинград фронтында ул “Батырлык өчен медале белән бүләкләнә. Ләкин ул бу бүләкне алу бәхетенә ирешә алмый. 1942 елны Сталинград янында гитлерчыларга каршы бәрелештә аларның танкы яна башлый. Снарядлар да, патроннар да санаулы гына. Тынып калган танкны фашистлар сырып ала. Алар танкистларга бирелергә куша. Экипаж командиры Әсхәт Кәбиров яна торган танкны дошман

колоннасына алып китә... Каты шартлау дошман өерен тар-мар итә. Лейтенант Әсхәт Кәбиров әнә шул сугышта һәлак була. Бу батырлыгы өчен ул Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Бөек Ватан сугышында
Югалтса да ана баласын,
Олы шатлык- Җиңү тантанасы
Дәвалады йөрәк ярасын.
Үлде дибез, алар үлмәделәр,
Мәңге яшәр алар йөрәктә
Җиңү яулап, шат тормышны
Калдырдылар безгә бүләккә.

Иске Шөгер мәктәбе укучылары Әсхәт Кәбировның истәлекләрен кадерләп саклыйлар. Аның бертуган апасы Сәрия апа белән озак еллар элемтәдә торганннар. Лира Александровна җитәкчелегендә аның белән Казан шәһәрендә очрашканнар. Сәрия апа ярдәме белән альбом да төзелгән. Мәктәптә “Батырлык Дәресләре” дә Әсхәт Кәбировның якты истәлегенә багышлана.

Җырлап үләрбез.
Сез белегез, дөнья козгыннары,
Помещиклар, байлар, түрәләр.
Бөек Совет иле кешеләре
Үлгәндә дә җырлап үләләр.
Атыш кызды, тик яралы
Танк кына хәзер атмады.
Пуля бетте, ә ян якта
Гарнаталар һаман шартлады.
Алар өчәү соңгы патронгача
Дошманнарга каршы тордылар.
Гусеница ватык, пуля бетте,
Һәм ирексез алар тындылар.
Дошманнар да совет танкысының
Пулялары бетүен белделәр.
Дошман этләр курка-курка гына
Танкка якын ук килделәр.
Ләкин танк һаман эндәшмәде.
Танк атмый, танк яралы.
Дошман офицеры танкистларга
Бирелергә өндәп карады.
Батыр совет танкистлары
Кискен итеп җавап бирделәр
-Дошман кулына тереләй бирелүне
Совет кешеләре белмиләр!
Тагын:”Бирелегез!”- дип кабатланды,
Танк бирелмәде...ә астына
Фитиль салып фугас салынды.
Шул чагында совет танкистлары
Дошманнарга отпор бирделәр.
Советларның герой солдатлары

Данлы үлем белән үлделәр.
Әсхәт Кәбиров.
1941 ел.

## Апрель.

Озакламый шомырт чәчәк атар,
Гөлләр узыша-узыша үсәрләр
Җир өстенә кояш нурын сибәр,
Кызыл алмалар да пешәрләр.

Җиргә үскән һәрбер үләнгә дә
Һәр чәчәккә сөеп карыйм мин.
Совет гражданы булуымны
Бөек бәхет диеп саныйм мин.

Бүген генә әле зәңгәр күктә
Көлеп йөрде апрель кояшы.
Бүген утызынчы апрель диеп
Хатлар язды кешелек дөньясы.

Ә иртәгә бөек ил өстенә
Май кояшы карап елмаер.
Һәм аңардан Бөек Совет иле,
Бөек Ватаныбыз нур алыр.
Әсхәт Кәбиров.
1936 ел.

Әсхәт Кәбировның әтисе Могыйн Кәбиров партизан, революционер була. 1917 елга кадәр төрле мәктәпләрдә укытучы булып эшли. Октябрь революциясеннән соң ул Васинский волостендә беренче председатель була. Гражданнар сугышы елларында ул ак бандитларга каршы партизан отряларында сугыша. Аклар кулга алып асарга җыеналар, ләкин Кызыл Армия вакытынада килеп җитеп, аны коткара. 1934 елда үлә.

Әсхәт Кәбировның әнисе Диләфрүз Кәбирова Мулланур Вахитовның туганы (Диләфрүз апаның энесе Мулланур Вахитовның дәү әнисе белән бертуган) үз малаенда барлык яхшы сыйфатларны тәрбияләгән. Партизан хатын буларак, бик күп авырлыклар, кимсетүләр күрергә туры килә. Ачлыктан, эпидемиядән аның алты баласы вафат була. Ул аз белемле була, ләкин шуңа карамастан, политик яктан бик тотнаклы була. Ул яшерен агитацияләрне, патшага каршы үткәрелә торган яшерен җыелышларны белә, ләкин аның авызыннан беркем, берсүз ала алмый. Ул Ижевск заводының эшче кызы була. Ирен асарга җыенганда аны да асарга телиләр, ләкин ул кача. Аклар аларның барлык әйберләрен тартып алалар, ләкин ул барысына да түзә. Бердәнбер улы Әсхәтне ул туган иленең патриоты итеп тәрбияли. 72 яшендә ул үлә.

Әсхәт Кәбировның апасы Сәрия апа Кәбирова энесен тәрбияләүгә зур өлеш кертә. Сәриа апа 1905 елның мартында Пермь губернасының Иштерәк

авылында туа. 1922 елны Казанга килеп, педагогия техникумына укырга керә. 1919 елда ул комсомолга керә. 1939 елдан КПСС члены. У бөтен гомерен һәм хезмәтен комсомол һәм партия эшенә бирә.

Үзенең тормыш иптәше Каюм абый белән Сәрия үзешчән сәнгать түгәрәгендә актив катнашып, һәрвакыт уңышлы чыгыш ясый торган булганннар.

Иске Шөгер мәктәбе укучыларына юллаган хатында ул түбәндәгеләрне яза:

“Иске Шөгер мәктәбе укчылары һәм хөрмәтле укытучыларылар! Сезне Бөек бәйрәм белән тәбрик итәм. Бу бәйрәмдә мәктәптәшегез Әсхәт Кәбировны искә алуыгызны үтенәм... Ул 16,5 яштә Шөгердән беренче доброволец булып китте, 18 яшьтә танк командиры булган. 1942 елның июлендә Сталинград сугышында һәлак булды. Аның җирлап үләрбез дигән шигере С.Шакирның “Солдат хатлары” дигән китабында.

Хушыгыз!

Сезгә сәламәтлек, зур уңышлар теләп Сәрия Кәбирова. 18 февраль 1978 ел.” Хәзерге көндә Сәрия апа вафат.

Гафиятов Фатих Әхтәм улы- капитан, 1926 елда туган,1943-1954 елларда армиядә хезмәт иткән. Хезмәт Кызыл байрагы ордены, “ Хезмәттәге батырлык өчен” һәм башка күп медаль белән бүләкләнгән. Хәзер Лениногорск шәһәрендә яши.

Сахапов Хәмит Фатих улы- майор, 1930 елда туган, 1948 елдан башлап армиядә хезмәт итә.

Сахапов Рубис Фатих улы- майор, 1934 елда туган. 1950- 1980 елларда армиядә хезмәт иткән.Хәзер Брежнев шәһәрендә яши.

Хамзин Әбузар Гөбәйдулла улы- майор, 1928 елда туган, 1950- 1978 елларда армиядә хезмәт иткән. Хәзер Николаев шәһәрендә яши.

Садриев Ягъфәр Габделхак улы- полковник, 1946 елда туган, 1964 елдан башлап хезмәт итә, хәрби академия тәмамлаган. Хәзер Камчаткада хезмәт итә.

Фасеев Энгель Салих улы- медицина хезмәте полковнигы, 1934 елда туган, 1954 елдан башлап армиядә хезмәт итә, хәрби академия тәмамлаган. Хәзер Тбилиси шәһәрендә яши.

Вильданов Галим Вильдан улы- лейтинант, 1912 елда туган, 1933- 1943 елларда армиядә хезмәт иткән, 1943 елда Бөек Ватан сугышында һәлак булган.

Миннибаева Гамбәр медицина хезмәте лейтинанты, 1920 елда туган, Бөек Ватан сугышында катнашкан. Хәзер Робно шәһәрендә яши.

Шафигуллин Ислам Шәһит улы- майор, 1927 елда туган, 1944- 1970 елларда армиядә хезмәт иткән. “Сугыш хезмәтләре өчен” һәм башка күп медальләре белән бүләкләнгән. Хәзер Лениногорск шәһәрендә яши.

Нәбиров Әсгать Могыйн улы-лейтенант, 1924 елда туган.Сталинград өчен сугышларда “Батырлык өчен” медале белән бүләкләнә.1942 елда 18 яшьлек лейтенант батырларча һәлак була.Үлгәннән соң Кызыл йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Шәрәфетдинов Фәсхетдин Мөхетдин улы-өлкән лейте-нант,1923 елда туган,1941-1946 елларда Бөек Ватан сугышында катнашкан,Кызыл йолдыз,Ленин орденнары,күп медальләр белән бүләкләнгән.

Социалистик Хезмәт Герое.

Хәзер Минзәлә шәһәрендә яши.

Шарифуллин Зиннәт Галиулла улы-лейтенант,1916 елда туган,1937- 1946 елларда армиядә хезмәт иткән,Бөек Ватан сугышында катнашкан,1 дәрәҗә Ватан сугышы,Кызыл йолдыз,Ленин һәм Хезмәт кызыл байрагы

“Батырлык өчен” һәм башка медальләр белән бүләкләнә.Хәзер Әлмәт шәһәрендә яши.

Максимов(Мәгъсүмов) Мәгънәви Мәгъсүм улы- кече лейтенант,1919 елда туган,1941- 1946 елны Бөек Ватан сугышында катнашкан,2 мәртәбә Кызыл йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.1983 елда үлгән.

Билалов Йосыф Миргасим улы- 1912 елда туган, 1934 - 46 ел-ларда армияда хезмәт иткән Бөек Ватан сугышында катнашкан. Кызыл йолдыз, I дәрәҗә Ватан сугышы – ордины, “Хәрби хезмәтләре өчен” һәм башка медалҗләр белән бүләкләнә.

Харисов Гариф Харис улы –Капитан. 1944 елда туган, Бөек Ватан сугышында катнашкан.
13 орден һәм медалҗләр белән бүләкләнгән.

Ханипов Мөнир Хәниф улы – кече лейтинант. 1917 елда туган, 1938 – 1943 елда армияда хезмәт иткән, 1943 елда һәлак булган. I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

Садриев Фәрит Мәгъсүм улы – леөтинант. 1923 елда туган, 1942 елда Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган.

Фахертдинов Фаррах
Шамсутдинов Хәмәт
Самигуллин Зыя
Хәертдинов Хәләф
Нуртдинов Фәрхетдин
Хисматуллин Исхак
Загретдинов Закир
Юнусова Җәүхәрия
Хайруллина Мөхтәрәмә
Сидоров Петор
Шигапов Разак
Бангаров Габделхак
Харисов Мирсәяф
Кашипов Шафик
Салахетдинов Галәлетдин
Хазипов Мизбах
Ахметшин Фәрекша
Ахат Ашапов
Билалов Йосыф

Борханов Хәмзә
Вәлиев Хәлиулла Нурлыгареев Сабир
Ахметзянов Әхмәтҗан
Вильданов Кыям
Мавлютов Авзал
Мавлютов Ризак
Садриев Инсаф
Хусаинов Вәли
Гымаев Ризак
Даутов Абдулла
Сафин Габделхак
Бадертдинов Шәрип
Каюмов Габдрахман
Хуббатуллин Гарифулла
Саматов Рәхим
Насыртдинов Котдус
Хабибуллин Гатиятулла
Габидуллин Зәйнулла
Сәлимҗанов Нигъматҗан
Зыятдинов Гаяз
Хәертдинов Кашап
Шәрифуллин Нәби
Газимҗанов Рәхимҗан
Бәдертдинов Рәүф
Шәрәфетдинов Фәсхетдин
Шәрифуллин Зиннәт
Фәтхетдинов Ислам
Сафиуллин Морат
Михтанов Барый
Җиһаншин Кәрам
Мингазов Шәех

Сафин Һади
Хәмидуллин Касыйм
Галиев Гамир
Бәдертдинов Кыям
Кәримов Мәхмүт
Ханипов Рәүф
Садриев Бәкер
Гараев Шакир
Тахауов Кыям
Гильманов Ягъфәр
Хәмзин Зөфәр

Таҗиева Сәрия
“Шушма” колхозының терлек симертүчесе.
Хәмидуллин Касыйм
“Шушма” колхозының хезмәт ветераны.
Шигапова Гөлчирә
“Шушма” колхозының сыер саву операторы.
Валиева Ярия
Шөгер ател-есы тегучесе.
Гыйззәтуллин Мөхтәр
ШНБЗда эретеп ябыштыручы.
Хәсәншин Тәлгат-
“Шушма” колхозы механизаторы.
Бәдертдинова Сабира
Иске Шөгер балалар бакчасы тәрбияче-методисты.
Низамова Нәзирә
Шөгер кирпич заводы эшчесе.
Сөләйманов Илгизәр
Янгын сүндерүче.

Хәертдинов Роберт
“Шушма” колхозы механизаторы.
Музеева Зөлфирә
Шөгер кирпич заводы эшчесе.
Вәлиев Әбүзәр
Шөгер мелиора-ия шоферы.
Кашипова Гөлсем
Иске Шөгер кибете сатучысы.
Гыйззәтуллин Фәрит
“Шушма” колхозы шоферы.
Юнысов Әсхәт
“Шушма” колхозы механизаторы.

Хәйруллина Мөхтәрәмә һәм Юнысова Җәүһәрия апалар.

Юнысова Җәүһәрия апа.

Сугыштагы хатын-кызлар.

Хәйруллина Мөхтәрәмә(уртада) һәм
Шакирова Зәйнәп (2 рәт, сулда)
Җиңү көнендә сугышчан дуслары белән.

Хөснетдинова Мәкбүлә, Вильданова Хәлимә,
Билалова Расимә.

Юнысова Җәүһәрия һәм Хәйруллина
Мөхтәрәмә апалар полкташлары Оличенко белән.

Дәүләт Музееның Бөек Ватан сугышы
бүлмәсендә Әсхәт Кәбиров почмагы.

Әсхәтнең әтисе- Могыйн Кәбиров.

Әсхәтнең әнисе- Диләфрүз Кәбирова.

Әсхәт Кәбиров.

Бәдертдинова Зәйнәп
Хезмәт Кызыл Байрагы ордены
белән бүләкләнде.
Вәлиев Миргасыйм
Хезмәт Кызыл Байрагы ордены
белән бүләкләнде.
Минәхмәтов Барый
Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.
Шигапова Гөлчирә
Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.
Әхмәтҗанов Габдулла
Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.
Бәдертдинов Ядкәр
Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.
Хөббәтуллин Җәдит
Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.
Нурлыгәрәев Сабир

“Аеруча хезмәттәге батырлыгы өчен” медале белән бүләкләнде.
Әхмәтҗанов Ислам
“Хезмәттәге батырлыгы өчен” медале белән бүләкләнде.
Халимова Лира
“Хезмәттәге батырлык өчен” медале белән бүләкләнде.
Гыймаева Мөхтәрәмә
“Аеруча хезмәттәге батырлыгы өчен” медале белән бүләкләнде.
Бадыйков Әбүзәр
“Аеруча хезмәттәге батырлыгы өчен” медале белән бүләкләнде.
Нурлыгәрәев Җәмил
РСФСРның атказанган укытучысы.
Рәхимов Җәмит
ТАССРның атказанган культура работнигы.
Хәлимов Салих
“Хезмәттәге батырлык өчен” медале белән бүләкләнде.
Аглиуллина Хәмидә
“Хезмәттәге батырлык өчен” медале белән бүләкләнде.
Абдуллина Әнисә
“Хезмәттәге батырлык өчен” медале белән бүләкләнде.
Гыймаев Рәис
“Аеруча хезмәттәге батырлык өчен” медале белән бүләкләнде.
Гирфанова Нурия

“Аеруча хезмәттәге батырлык өчен” медале белән бүләкләнде.
Сафина Чәчкә
“Аеруча хезмәттәге батырлык өчен” медале белән бүләкләнде.
Бадыкова Тәскирә
“Аеруча хезмәттәге батырлык өчен” медале белән бүләкләнде.
Зиннуров Энгель
Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.
Рафиков Раиф
Ленинның 100 еллык юбилей медале белән бүләкләнде.
Хафизов Рәис
Ленинның 100 еллык юбилей медале белән бүләкләнде.

МӘКТӘП ДИРЕКТОРЛАРЫ

АТКАЗАНГАН УКЫТУЧЫЛАР

Индус Таһиров

Роза Хафизова

Җәүдәт Дәрзаман

Камиль Фасеев

Җәмит Рәхимов

Касыйм Тәхау

***Фасееев Камиль Фатыхович.***

Танылган дәүләт эшлеклесе һәм галим, элеккеге ТАССР Югары Совет Президиумы Рәисе.

К.Ф.Фасеев Самара губернасы Бөгелмә уезды Яңа Печмән волосте Тимәш авылында туа. Үзенең хезмәт биографиясен ТАССРның Шөгер районында укытучы булып 1936 елда башлый. 1939-1943 елларда ВЛКСМның Шөгер райкомы секретаре, ТАССРның Яңа Печмән райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире. 1953 елда ЦК КПССның иҗтимагый фәннәр Академиясен тәмамлагач, фән һәм мәдәният бүлеге мөдире булып эшләгән, ТАССР Югары Советы Президиумы Рәисе. РСФСР һәм ТАССР Югары Советларына депутат итеп сайлана. 1959-1963 елларда РСФСР Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары була.

1960 елдан Камил Фатыхович Фасеев фәнни һәм педагогик эшчәнлек белән актив шөгелләнә башлый: өлкән фәнни хезмәткәр, СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, соңрак- доцент, профессор, В.И.Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының фәнни коммунизм кафедрасы рәисе. Соңгы көннәренә кадәр Казан дәүләт университеты белән бәйләнгән, профессор-консультант булып эшләгән, философия фәннәре докторы.Ике “Почет Билгесе” ордены, өч медаль белән бүләкләнгән. “ТАССРның атказанган фән эшлеклесе”.

Иске Шөгер авылында беренче колхоз 1931 елда оештырылды. Колхозга “Үзәк” исеме бирелә. Колхозның 1 нче председателе.

| | |
|---|---|
| Хамзин Гөбәйдулла. | 1931. |
| Таһиров Ризатдин. | 1932-33. |
| Шакирзянов Газизҗан. | 1934-37. |
| Газизов Гариф. | 1937-38. |
| Зарипов Гариф. | 1938-39. |
| Садыков Шакир. | 1940-41. |
| Зарипов Гәрәй. | 1941-43. |
| Нуриев Хәсән. | 1943-44. |
| Корбанов. | 1944-45. |
| Валиев Гариф. | 1945. |
| Саматов Рахим. | 1945-46. |
| Зарипов Харис. | 1946-47. |
| Шарифуллин Зиннәт. | 1947-49. |
| Нуриев Хәсән. | 1949-50. |
| Ахметов Зыя. | 1950-66. |
| Шаймарданов Насих | 1966-72. |
| Зайдуллин Миргаси. | 1972-76. |
| Гимаев Атлас. | 1976. |

Авыл Советы председательләре.

Тагиров Ризак.
Шарипов Могин.
Хасаншин Мобаракша.
Вильданов Шакир.
Нуриев Хәсән.
Нагимов Аюп.
Мусин Ахмет.
Каримов Махмут.
Зарипов Хөсәен.
Гильманов Салих.
Мухаметзянов Рәйсә.
Гимаев Равиль.

Роза Хафизова.

Роза Сәет кызы Хафизова.1929 елның 6 февралендә
АССРның Бөгелмә шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туган.Та
хәзерге Лениногорск районы Сарабиккол авылында җиде клас
Шөгер урта мәктәбендә ун класс тәмамлаганнан соң, 1947-19
В.И. Ульянов- Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты
филологиясе бүлегендә югары белем ала.

1952-1960 елларда ул "Татарстан яшьләре", Чис
газетасында,Казандагы күптиражлы "Төзелештә" газета ред
әдәби хезмәткәр,КПСС Өлкә комитеты каршындагы Парт
институтында фәнни хезмәткәр һәм Татарстан китап нә
редактор булып эшли.1962 елда "Ялкын" журналының баш
итеп билгеләнә.

1974 елда Татарстан АССРның, 1983 елда РСФСРның
культура работнигы дигән мактаулы исем бирелде.

Истәлекләр: "Бөгелмә каласында туганмын. Әмма туган ж
өч төбәкне саныйм: беренчесе- әтием,Хафизов Мирсәет Хәмзә
үскән Бәйрәкә авылы (Ютазы районы),икенчесе- әнием Мәгъ
үскән Сарабиккол авылы. Балачагым гүзәл табигатьле шушы ав
Өченчесе-мин дөньяга килгән Бөгелмә каласы. Биредә тик
кадәр генә яшәгәнмен. Әтине Шөгер районына эшкә күчер
яшемә хәтле шушында яшәдек. Җидееллык мәктәпне Са
тәмамладым."

1946 елда Иске Шөгер урта мәктәбен тәмамлап,Казан
килдем.

Нәшер ителгән китаплары:

Кыңгыраулар җыры. 1967.
Таң билгесе. 1968.
Курай-малай маҗаралары. 1969.

| | |
|---|---|
| Кирлемән. | 1970. |
| Кашкарыйлар озын гомерле. | 1975. |
| Без әле кайтырбыз. | 1977. |
| Әкиятләр. | 1979. |
| Тантаналы вәгъдә. | 1981. |
| Киек каз юлы. | 1988. |
| Сак-сок тавышы. | 1987. |
| Ак тәпи ник моңая. | 1991. |

Индус Таһиров.

Индус Ризак улы Таһиров 1936 елда Иске Шөгер авы
Индус-интеллигент гаиләсеннән чыккан бала. Аның әтисе- Шө
Колхоз рәисе, авылы Советы башлыгы булган. Әнисе-Әминә
буе укытучы. Өч ир бала табып, шуларга сөенеп-куанып, як
белән яшәп ятканда,сугыш атлы бәладән башы чыкмаган СССР
афәт ябырыла. Беркемне дә урап үтмәгән, барлык ир-атны кыр
үз казанына кубарып алып кереп киткән Ватан сугышы. Акти
ага, аңлашылса кирәк, беренче көннәрдә үк сафка алына. Ан
чыккан Суслангерга әзерлек узарга җибәрәләр.

Сугыш вакытында аны Чыршылы авылына мәктәп дире
җибәрәләр. Сугыш төгәлләнгәч,тагын Шөгергә. Индус
белемне татар мәктәбендә ала. Аннары рус теле мәктәпкә кү
килә. Яшәү шартлары тәмам хөртиләнгән, җиңелрәк булм
Әминә апа өч улы белән Әлмәткә, туганнары янына кайт
бүлегенә инспектор булып эшкә керә һәм пенсиягә чыкка
хезмәт итә.

Бала чакта ук Индуска китап җене кагыла. Уртамәктәп
төгәлләп, армиягә эләккәч тә буш вакытны буш итми, китаптан
Хезмәт итеп кайткач, Индус Казан дәүләт университеты
факультетына имтихан тота.

Шулай, 1963 елдан башлап Индус Ризакович язмышы у
белән бәйле. Актив студент, лидер, факультетның комсомол
секретаре,һәм, әлбәттә инде, фән. Аның гыйльми җитәкче
мөдире И. Ионенко аспирантурага керергә тәгъдим итә. Асп
чагында ук ул И.Ионенко белән берлектә, Казанда Октябрь ре
тарихы турында зур китап иҗат итә, вакытлы матбугатта
мәкаләләр бастыра. Кандидатлык диссертациясе яклаганнан со
ассистент, докторлык диссертациясе яклау, профессор, кафед
декан.

Демократия җилләре кузгалу белән Индус Ризаковичның талантлары ачылды.

Энесе Энгель Ризакович аның юлыннан китте. Хәзе җәмәгатьчелеккә билгеле галим,кафедра мөдире, улы-фәннәр Кыскасы, галимнәр гаиләсе.

Касыйм Тәхау.

Касыйм Тәхау- Тәхаутдинов Касыйм Нури улы Лениногорск районының Тукмак авылында дөньяга килгән.

9 нчы класста укыган җиреннән 17 яшьлек егет хәрби хезмәткә алына. Дөресрәге, шул елларның патриотик дулкынында үз теләге белән Ватанны сакларга ашкына. Яшь егетне Көнчыгыш чикләргә озаталар. Ихтимал, анда да хәтәрлек җитәрлек булгандыр.

1947 елны Иркутск шәһәрендәге хәрби авиация механиклары мәктәбен, аннары Казан хәрби авиация техник училищесын тәгәлли. Техник әзерлекле белгечне моторларга һәм самолетларга хезмәт күрсәтү башлыгы итеп билгелиләр. 14 ел чамасы хәрби хезмәттә булганнан соң Касыйм Тәхаутдинов кинәт кенә язмышында текә борылыш, очучылар теле белән әйткәндә, вираж ясый.

Виражның асыл сәбәбе, бәлки, болайдыр: инде хәрби погоннарга шактыйияләшкән егет бәхетен Хәрби академиядә сынап карарга ниятли. Ләкин татар егетенә чират җитми, төрле сәбәпләр табылып кына тора. Берәү булса, майор погоннарына тиенгәнче, хәрби хезмәттә һаман йөрер иде, ләкин Касыйм Тәхаутдиновның безгә шактый таныш тәвәккәл холкы үзенекен итә. Янәсе, алаймы, чират җитмиме, сөйгән Казанымда миңа һәрвакыт урын табылыр, ди дә Казанына кайтып китә.

1956 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүле-генә читтән торып укырга керә. 1962 елдан 1990 елга кадәр Татарстанның иң

өлкән, иң абруйлы газетасында- хәзерге “Ватаным Татарстан” редакциясендә әдәби хезмәткәр, өлкән әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире, җаваплы секретарь урынбасары вазифаларын башкара. Әйтергә кирәк, штыкны каләмгә алыштыр-ганына беркайчан да үкенми.

60 яшен тутыргач пенсиягә киткәндер, дисезме? Юк.1995 елга кадәр “Татарстан хәбәрләре” газетасында эшләде. Хезмәтенә күрә хөрмәтен дә казанды. Аның Татарстан Республикасының төрле оешмалары тарафыннан бирелгән Мактау язучылары бихисап.”Атказанган мәдәният хезмәткәре” дигән исеме бар.Журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге премиясе лауреаты да ул. Бөек Ватан сугышы чорында алган медальләре исә Җиңү көнендә күкрәген калкан кебек каплый.

Бөек Җиңүне бәйрәм иткән көннәрдә “Мәдәни җомга” газетасында Касыйм Тәхауның 1943 елда армиягә китеп барганда язган шигырьләр циклы басылып чыккан иде.

Бөек Ватан сугышы елларында аңа илнең көнчыгыш чикләрен япон самурайларыннан саклауда катнашырга туры килде. Баш очыбызда дошман туплары шартлап тормаса да, безнең солдатлар бик тә авыр шартларда хезмәт иттеләр.Үлем –китемнәр була торгач, ачлыкның да нәрсә икәнен татыганнар, башка җәфаларны да кичергәннәр.

1945 елның август аенда аларның 94 нче укчы дивизия, башкалар белән бергә, көчле ташкын булып, Квантун армиясенә ташланды.Сентябрь башында

самурайлар җиңелеп, кулларын күтәрергә мәҗбүр булдылар.

Касыйм Тәхау утлы елларда ике дистә чамасы шигырь язган.Ул чакта солдат кешегә шигырь язу турында уйланып йөрергә мөмкинлек бик тә аз булган.

Шигърият аның белән гомер буе янәшә яшәгән. Аның шигырьләренә хал-кыбызның куренекле композиторлары Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин, Александр Ключарев,Заһит Хәбибуллин, Сара Садыйкова, Әнвәр Бакиров җырлар яздылар.Татарстан китап нәшриятында биш-алты китабы дөнья күрде.Алар арасында мари, Питрәч, Лаеш урманнарында таяк һәм кәрҗин тотып тын ауда йөргәндә табылган, җиләкләргә, гөмбәләргә ияреп өйгә кайткан нәни хикәяләр-дән торган җыентык та, балалар өчен язылган шигырьләрдән тупланган “Куян күчтәнәче” китабы да бар.Газетабыз укучылары Касыйм Тәхауны “Табигать мизгелләре” сәхифхлхре буенча бик яхшы хәтерлиләр булыр. Өлкәнәеп, шактый тәҗрибә туплагач, булмаган сакалына шактый акыл урагач, ул безне “Гыйбрәтле гыйбарәләр” белән гаҗәпләндерә башлады.

1945 елда язылган “Үлем үзәне” дигән циклдан берничә шигырен тәкъдим итәм:

Печән чабабыз тайгада.

Сүнә йолдызлар таңгы чык сыман,

Үзән өстендә йөзә сөт томан.
Солдат мескенкәй йоклап һич туймый,
Инде быргычы “Подъем”ны уйный.
Торып, башларын нурга куялар,
Энҗе шикелле балкый кыялар.



Хайруллина Мөхтәрәмә.

Мөхтәрәмә апа 1922 елның 10 февралендә Шөгер районының Иске Шөгер авылында туа. Әнисе – Миңнеәсма Хөснетдин кызы һәм әтисе – Гарифулла Хайрулла улы бик авыр тормыш алып барган. Аларның гаиләсендә 8 бала булган һәм 5 енчесе булып Мөхтәрәмә апа туган. Алар барлыгы ике малай һәм алты кыз булганнар. Мөхтәрәмә апа бик авыр шартларда үскән. Кычыткан, балтырган, зәрдә ашлары ашап үскәннәр. Ул үзе дә:

- Күрше остабикә әбидән бер кашык тоз сорап керә торган идек, - ди.

Балаларын ач калдырмас өчен, әниләре үзләренең хуҗалыкларында күп итеп бәрәңге, тары, пәҗә һәм башка үсемлекләр үстергән, ситса суктырып киемнәрне дә үзе тегеә торган булган.

1933 елны 17 яшендә Мөхтәрәмә апаның олы апасы Мөнәвәрә дробилкада тапалып үлгән. 1934енче елны 47 яшендә әтисе үпкә чиреннән үлә. әтисе үлгәч тә,Мәхтхрәмә апаның абыйсы Инсафетдин зводтагы хоз. частька эшкә урнаша. Ләкин 1940 нчы елда йөрәк өянәге белән ул да үлеп китә. Шуннан соң бөтен тормыш авырлыклары Миңнеәсма апа җилкәсенә төшә.

Мәхтәрәмә апа сигез классны укып бетергәч, завод конторына счетовод булып эшкә урнаша. Аннан соң аны завод шахтосына күчерәләр. Ләкин анда бер ел да эшләми, гудроннар бетү сәбәпле, шахтаны япканнар. Шахта ябылгач, завод дирек-торы Мөхтәрәмә апаны

Шөгер районы Райпосына бухгалтер ясап эшкә алган.

1941 елда, сугыш башлангач, Мөхтәрәмә апаны Шөгер районы авыл советына счетовод итеп алалар. Анда ул берюллы счетовод та, секретарь да, начальник ВОЗ да булып эшли. Шул елларда аның аша 1енче партиядә - егетләрне, 2 енче партиядә кызларны сугышка алып киткәннәр, ә 3 енче партиядә Мөхтәрәмә апа эләккән. Шулай итеп, Мөхтәрәмә апа сугышка 1943 елның 22енче июнендә киткән.

Сугышның беренче көннәрендә аларны поезд белән Казанга илткәннәр. Казанга кич белән генә барып төшкәннәр. Ул кызлар арасында Хөснетдинова Мәкбүлә, Вилданова Хәлимә, Дау-това Наилә, Билалова Рәсимә, Шакирова Зәйнәп, Бадыкшанова Зәйнәп һ.б. барлыгы – 22 кыз, үзләре теләп, фронтка китәләр. Икенче көнне Мөхтәрәмә апаны һәм башка солдатларны пушкадан атарга өйрәтәләр. Бу хәзерлек курслары 3 ай дәвам итә.

Шуннан соң Мөхтәрәмә апаларның сугышчан юллары Белоруссиянең Сарын шәһәрендә 1873 енче зенитно-артилерейский полкның 4енче һәм 5 енче дивизионнарында башлана. Аннары соң аларны Гомель, Ковель, Брест шәһәрләренә күчерәләр. Бөтен шәһәрләрдә дә Мөхтәрәмә апа зенитчы булган. Озак барган шушы сугыш елларында, төннәр буе алар күккә карап, дошманның самолетларын бомбага тота торган булганнар. Ә көндезләрен исә снарядлар чистарт-каннар, яраланган солдатларны дәвалаганнар. Шулай итеп, көне-төне йокламыйча, алар безнең киләчәгебез әчен дошманга каршы сугышканнар. Мөхтәрәмә апа әйтүенчә, кораллар җткән, снарядларны да китереп

торганнар, ә ашау ягы мәсьәләсене бик авыр булса да, ашарга да булган, ачка үлмәгәннәр. Көнгә 400 грамм ипи, шулпа, бәрәңге, умач кебек әйберләр белән туклангганнар. Бер пушкада алар җиде кеше булганнар – 1- командир, 1се әйләндерә торган, 2 кеше наводчиклар, 1 кеше заряжатель, 2 кеше – патрон бирүчеләр.

Дошман самолетларын аткан вакытта, Мөхтәрәмә апаның бармагына снаряд кыйпылчыгы тиеп, беразын кисә. Ләкин ул аны, самолетлар китеп беткәс, сугыш кыры бераз тынычлангач кына күрә. әле аны да командир взвода әйтә. Шундый хатирәләр Мөхтәрәмә апаның күңеленнән беркайчан да китми.